Педагогик киңәшмә утырышында
каралды һәм кабул ителде.
Беркетмә № 1 “26” 08 2021 ел.

РАСЛЫЙМ
№ 9 нчы ”Садко” балалар бакчасы
мөдире ________ Н.А.Комарова
№85 «26» августа 2021гел

Татарстан Республикасы “Әлмәт шәһәре
9 нчы “Садко” балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе
татар теле тәрбиячесенең

# 2021 – 2022 уку елына
# эш программасы


Төзеде: Усманова Гөлнур
Мөхәмәт кызы
югары категорияле
татар теле тәрбиячесе


Әлмәт шәһәре, 2021 ел

## Программаның структурасы

**Кереш** ………………………………………………………………… 2
**I. Программаның максатлары**
1.1. Аңлатма язуы……………………………………………………………3
1.1.1. Максатлар һәм бурычлар……………………………………………… 4
1.1.2. Программа принциплары………………………………………………… 5
1.2 Максати ориентирлар………………………………………………… 6
1.3 Көтелгән нәтиҗә……………………………………………………7
**II. Программаның эчтәлеге**
2.1. Укыту-методик комплектның эчтәлеге…………………………………… 8
2.1.1. «Минем өем» проекты……………………………………………………8
2.1.2. «Уйный-уйный үсәбез» проекты……………………………………………12
2.1.3. «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар» проекты………………… 19
2.2. «Туган телдә сөйләшәбез» проекты……………………………………… 24
2.3 Милли-төбәк компоненты Программасы…………………………………… 50
**III. Оештыру өлеше**
3.1. Методик киңәшләр, оештыру тәртибе, эш төрләре……………………………53
3.2. Диагностика материаллары, аны үткәрү…………………………………… 57
3.3. Методик әсбаплар…………………………………………………………71
3.4. Милли состав……………………………………………………………… 73
3.5. Файдаланылган әдәбият………………………………………………… 74

# I. Программаның максатлары

## 1.1. Аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту методик комплектлары (УМК) төзелде. Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен, “Минем өем” (4-5 яшь), “Уйный – уйный үсәбез” (5-6 яшь), “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” (6 - 7 яшь) проектларын үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән. Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора. Яңа сүз өйрәткәндә, сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә; төрле эш формаларында (пышылдап, кумәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә; уеннар кулланып (“Ватык телефон”, “Кайтаваз”...) ныгытыла; хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырыла: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин”. Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә кулланганда “Бу кем?”, “Кем юк?”, “Кәрзиндә нәрсә бар?”, “Нәрсә юк?”, “Серле янчык”, “Әйе-юк”, “Дөресен әйт” дидактик уеннары уйнала. Аралаша белү күнекмәләре булдырганда “Әйдәгез танышабыз”, “Кунакны сыйла”, “Кибеттә”, “Кафеда”, “Телефоннан сөйләшү”уен ситуацияләре оештырыла. Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла. Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала. Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана. Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла. Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм эти-әниләрнең бердәм

позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем 4 учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора. Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели. Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән. Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартын күздә тотып, укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде.

**Норматив – хокукый документлар:**

**Федераль җирлегендә:**

• 29.12.2012елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;

• Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган);

• СанПиН 2.4.1.3049-13 « Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр" раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2013 ел 15 май 26 нчы номерлы боерыгы;

• "Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру" (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август 1014 нче номерлы боергы);

**Төбәк җирлегендә:**

• Татарстан Республикасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;- Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында" Законы;

**Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:**

• "Әлмәт шәһәре 9 нчы "Садко" балалар бакасы" мунципаль мәктәпкәчә белем учреждениесенең Уставы;

• "Әлмәт шәһәре 9 нчы "Садко" балалар бакасы" мунципаль мәктәпкәчә белем учреждениесенең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;

### 1.1.1. Максатлар һәм бурычлар

«Татарча сөйләшәбез» дип аталган методик комплект балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма,күрсәтмә һәм таратма әсбаплар, аудио- һәм видеоматериаллар, балалар өчен эш дәфтәрләре туплап бирелгән. Методик комплектлар өч яшь төркеме (уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) өчен әзерләнде, һәм аларның барысы да “Татарча сөйләшәбез” дип исемләнә. Бүгенге социолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа укыту-методик кулланмалар эшләү зарурлыгы килеп басты.

Билгеле булганча, телгә өйрәтүнең максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле өйрәтү максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

Балаларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, балалар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Татарча сөйләшергә өйрәткәндә куелган минимум бурычлар.**

Программа өч проектны һәм аларның төп максатларын һәм бурычларын үз эченә ала:

**“Минем өем” проекты (4-5 яшь).**

Максат: Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты (5-6 яшь).**

Максат: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь).**

Максат: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар:1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

### 1.1.2. Программа принциплары

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

*Интеграция һәм дифференциация принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:* аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

*Белем бирүне комплекслы-тематик принципка корып оештыру;*

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы* - гадидән катлаулыга таба бару.

*Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

## 1.2. Максати ориентирлар

**Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.**

1.Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

**Эш төрләре һәм формалары.**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

### 1.3. Көтелгән нәтиҗә

**Баланың сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы** күздә тотыла:

- өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча тәрбияченең сорауларына жавап  һәм сораулар куя белү;
- бирелгән үрнәк диалоглар буенча охшаш диалоглар төзү, әңгәмәдә катнаша алу;
- терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына,үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый.  Телне өйрәтү процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын ойрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә.  Материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик – грамматик материалны балаларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым.Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә.  Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр шөгыльгә  программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Шөгыльләрдә ситуатив күнегүләрнең рус һәм татар телендә бирелүе балаларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора. Комплектларның төп максаты балаларны аралашуга өйрәтү.

## II. Программаның эчтәлеге

### 2.1 Укыту методик комплектының эчтәлеге

Һәр проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар һәм әти-әниләр өчен эш дәфтәрләре;

4) аудиоязмалар;
5) анимацион күренешләр;
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

**2.1.1. «Минем өем» проекты. (**4-5яшьлек балалар өчен)
**Лексик минимум** – якынча 62 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.
**Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз)
**Сөйләм үрнәкләре:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)
**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- гаилә
- ашамлыклар
- уенчыклар
- саннар

Атна дәвамында 20 шәр минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

**Тематик план.**

| Актив сузләр | Сөйләм урнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм |
|---|---|---|
| **Гаилә – 18 сәгать (1-18)** | | |
| әти<br>әни<br><br>малай<br>кыз<br><br>мин<br>исәнмесез | -Бу кем?<br>-Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем юк?<br>-Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).<br><br>-Исәнмесез.<br>-Син кем? | Аудиоязма №1-23<br><br>Дәфтәрдә эш №1-4<br><br><br><br>Мультфильмнар:<br>1. “Әйдәгез, дуслашыйк” |

| | | |
|---|---|---|
| сау булыгыз<br><br><br><br>исәнме<br><br><br>эт<br>песи<br><br><br><br><br>әйе<br>юк<br>сау бул<br><br><br>әби<br>бабай<br><br><br><br><br><br><br><br>әйбәт | -Мин Коля (Оля).<br>-Мин малай.<br>-Сау булыгыз!<br><br>-Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>-Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем анда?<br>-Мин песи. Мин Мияу.<br>-Кил монда.<br>-Мин эт. Мин Акбай.<br>-Кил монда.<br><br>-Син Коля?<br>-Әйе, Коля.<br>-Син малай (кыз)?<br>-Әйе (юк).<br><br>-Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Әйе.<br>-Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Юк.<br>-Малай?<br>-Юк, кыз.<br>-Кыз?<br>-Әйе, кыз.<br>-Хәлләр ничек?<br>-Әйбәт. | 2. “Качышлы уйныйбыз”<br>3. “Шалкан” |
| **Ашамлыклар – 12 сәгать (19-30)** | | |

| | | |
|---|---|---|
| ипи<br>мә<br>рәхмәт<br><br>алма<br>сөт<br>чәй<br><br>тәмле<br>кил монда<br>утыр<br><br><br><br><br>аша<br>эч | -Мә, ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт, әби.<br><br><br>-Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт.<br><br><br>-Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля)<br>-Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>-Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт.<br>-Мә, тәмле алма (ипи).<br><br>-Мә, ипи (алма) аша.<br>-Мә, сөт  (чәй) эч. | Аудиоязма №24-39<br><br><br>Дәфтәрдә эш №5-10<br>Мультфильмнар:<br>1.“Тәмле” кибетендә”<br>2. “Азат кунак чакыра” |
| **Уенчыклар – 18 сәгать (31-48)** | | |
| туп<br><br><br>бир<br><br><br>зур<br>кечкенә<br><br><br><br>матур<br>курчак | - Бу нәрсә?<br>- Туп (курчак, куян, аю).<br><br>-Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>-Мә, курчак (туп, куян, аю).<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>-Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт). | Аудиоязма №40-53<br><br><br>Дәфтәрдә эш №11-13<br><br><br>Мультфильмнар:<br>1. “Паркка сәяхәт”<br>2. “Уенчыклар үпкәләгән”<br>3. “Күңелле уеннар”<br>4. “Акбай һәм Мияу мажаралары” |

| | | |
|---|---|---|
| куян<br>аю<br>уйна | -Аю (курчак, куян, туп)?<br>-Әйе.<br>-Курчак (аю, куян, туп)?<br>-Юк.<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br><br>-Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна.<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә. | |
| ю | - Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә  аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).<br><br>-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю. | |
| хәлләр ничек? | - Исәнме, Мияу!<br>- Исәнме, Акбай!<br>- Хәлләр ничек?<br>- Әйбәт. | |
| пычрак<br>чиста | -Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю. | |

| | | |
|---|---|---|
| | -Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак.<br>(Әйе, туп чиста).<br>Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| **Саннар - 6 сәгать (49-54)** | | |
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Мультфильм:<br>1.“Уйный-уйный саныйбыз” |
| **Кабатлау - 6 сәгать (55-60)** | | |
| | | Аудиоязма №25<br>Дәфтәрдә эш №61-64<br>Мультфильм:<br>1. “Күңелле ял итәбез” |

**2.1.2. «Уйный – уйный үсәбез» проекты. (**5-6 яшьлек балалар өчен)

**Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)

**Сөйләм үрнәкләре:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз).

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- яшелчәләр
- ашамлыклар
- савыт- саба
- киемнәр
- шәхси гигиена
- өй җиһазлары
- бәйрәм “Туган көн”
- бәйрәм “Сабан туй”
- Уртанчылар төркемендәге темалар(гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

Атнага 25 шәр минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

**Тематик план.**

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм** |
|---|---|---|
| **Кабатлау – 3 сәгать (1-3)** | | |
| | “Минем өем” проекты буенча | Аудиоязма №1<br>Дәфтәрдә эш №1<br>Мультфильм:<br>1. “Шалкан” |
| **Яшелчәләр – 21 сәгать (4-24)** | | |
| кишер<br><br><br><br>баллы<br><br>ничә | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә, кишер.<br><br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) | Аудиоязма №2-24<br><br>Дәфтәрдә эш №2-6<br><br>Мультфильмнар:<br>1.“Баллы кишер”<br>2. “Уйный-уйный эшлибез”<br>3. “Юл маҗаралары” |

| | | |
|---|---|---|
| суган<br>бәрәңге<br><br>кыяр<br><br>кәбестә<br>нинди<br><br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз<br>ун | -Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Рәхмәт.<br><br>-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак)<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>-Мә кишер(алма), аша. Баллы?<br>-Әйе, баллы. Рәхмәт.<br><br>-Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, | 4. “Кем эшләми, шул ашамый” |

| | | |
|---|---|---|
| кызыл<br>сары<br><br>яшел | кәбестә, кыяр)<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>-Сау бул, Коля.<br><br>-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>-Бу туп.<br>-Туп (алма) нинди?<br>-Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>-Нинди туп (алма) юк?<br>-Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк. | |

| | | |
|---|---|---|
| нәрсә кирәк?<br><br>юа | -Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>-Кирәк.<br><br>-Коля, нәрсә кирәк?<br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>-Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br><br>-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа. | |
| **Ашамлыклар – 6 сәгать (25-30)** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, | Аудиоязма №25-29<br><br>Дәфтәрдә эш №7, 8<br><br>Мультфильм:<br>1.“Аш бүлмәсе” |

<table>
<tr><td></td><td>кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Савыт-саба - 6 сәгать (31-36)</td></tr>
<tr><td>кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр</td><td>-Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк).</td><td>Аудиоязма №30-37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Мультфильм:<br>1. “Өч аю”<br>2. “Чисталыкта - матурлык”</td></tr>
<tr><td colspan="3">Киемнәр - 6 сәгать (37-42)</td></tr>
<tr><td>күлмәк<br><br>чалбар</td><td>яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br>күлмәк (чалбар) юк.<br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).</td><td>Аудиоязма №38-43<br><br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Мультфильм:<br>1.“Киемнәр кибетендә”<br>2.“Шаян уенчыклар”</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| <br><br>ки<br><br>сал<br><br><br><br>йокла | -Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>-Курчак, йокла. | |
| **Шәхси гигиена – 3 сәгать (43-45)** | | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br>-Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44-48<br><br>Эш дәфтәре №13, 14<br><br>Мультфильм<br>1.“Ни өчен киемнәр югалган?” |
| **Өй җиһазлары – 3 сәгать (46-48)** | | |
| өстәл<br>урындык<br>карават | -Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават).<br><br>-Зур аю, мә зур карават (өстәл, урындык).<br>-Кечкенә аю, мә кечкенә карават (өстәл, урындык).<br>-Нәрсә кирәк?<br>-Карават (өстәл, урындык) кирәк.<br>-Нинди карават?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, | Аудиоязма № 49<br><br>Эш дәфтәре №15<br><br>Мультфильм:<br>1.“Маша һәм өч аю” |

| | | |
|---|---|---|
| | зәңгәр) караваt.<br>-Мә, зур караваt.<br>-Рәхмәт. | |
| **Бәйрәм “туган көн” – 9 сәгать (49-57)** | | |
| яратам<br><br><br><br><br><br><br><br><br>бар | -Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>-Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br><br>-Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>“Бар”, “Юк” сүзләрен кулланып “Гаилә”, “Яшелчә” “Уенчыклар” темаларын кабатлау.<br>Диалогларны кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | Аудиоязма №50-60<br><br>Эш дәфтәре №16-19<br><br>Мультфильм:<br>1. “Туган көн”<br>2. ”Кем нәрсә ярата?” |
| **БӘЙРӘМ “САБАНТУЙ”- 3 СӘГАТЬ (58-60)** | | |
| | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>“Гаилә”, “Яшелчә”, | Аудиоязма №61-63<br><br>Мультфильм:<br>1.“Сабантуй бәйрәме” |

| | | |
|---|---|---|
| | “Уенчыклар” темаларын кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | |

**2.1.3 «Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты**

6-7 яшьлек балалар (мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен якынча 60 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.
**Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә ярatasың?(пассив сүз)
Проектның эчтәлеге уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган.
Атнага 30 ар минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

**Тематик план**

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм** |
|---|---|---|
| син кем?<br><br>хәерле көн<br><br><br><br><br><br>тычкан<br><br><br>бу кем? | <br><br>-Хәерле көн, Оля (Коля).<br>-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби). | Аудиоязма №1 - 2<br><br>Аудиоязма №3 - 5<br>Дәфтәрдә эш №1<br><br>Мультфильм: “Мияу адашкан”<br><br>Аудиоязма №6<br>Дәфтәрдә эш №2<br><br>Аудиоязма №7 - 8<br>Дәфтәрдә эш №3 |

| | | |
|---|---|---|
| бу нәрсә?<br><br>нишли?<br>йоклый<br>утыра<br><br>ашый<br>эчә<br><br>нишлисең?<br>ашыйм<br>эчәм<br><br>уйный<br>уйныйм<br><br>утырам | -Песи нишли?<br>-Песи йоклый.<br><br>-Әни нишли?<br>-Әни утыра.<br><br>-Коля нишли?<br>-Коля ашый (эчә).<br><br>-Мияу, нишлисең?<br>-Ашыйм.<br>-Акбай, нишлисең?<br>-Эчәм.<br><br>-Оля (Коля), нишлисең?<br>-Уйныйм.<br><br>-Кая барасың? | Мультфильм:”Аю баласы дөнья белән таныша”<br><br>Аудиоязма №9 - 10<br>Дәфтәрдә эш №4<br><br>Аудиоязма №11<br><br>Мультфильм: “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай”<br><br>Аудиоязма №12<br>Дәфтәрдә эш №5<br><br>Аудиоязма №13 - 14<br><br>Мультфильм:<br>“Тату гаилә”<br><br>Аудиоязма №15<br><br>Аудиоязма №16 - 18<br><br>Мультфильм: “Юмарт аю”<br><br>Аудиоязма №19 |

| | | |
|---|---|---|
| барам | -Кафега барам. | Аудиоязма №20 |
| кая барасың? | -Син нишлисең? | Дәфәрдә эш №6 |
| син нишлисең? | -Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый) | |
| | | Мультфильм: “Кафега барабыз” |
| | | Дәфтәрдә эш №7 |
| | Туп, туп<br>Матур туп. | |
| сикер-сикерәм | Сикер-сикер,<br>Матур туп. | |
| | | Аудиоязма №21-23 |
| | Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә. | |
| сикерә | Песи сикерә (йөгерә). | |
| йөгерә | Төлке сикерә (йөгерә). | Мультфильм: |
| төлке | | “Урманда күңелле уеннар” |
| | | Аудиоязма №24 |
| | -Йөгер! Син нишлисең?<br>-Мин йөгерәм. | Дәфтәрдә эш №8 |
| | | Аудиоязма №25-28 |
| йөгер-йөгерәм | -Мин чәк-чәк ашыйм. | |
| | -Мин өчпочмак ашыйм. | Мультфильм:<br>“Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” |
| чәк-чәк | | |
| өчпочмак | -Сиңа ничә яшь? | Аудиоязма №29-30 |
| | -6 яшь. | Дәфтәрдә эш №9 |
| | -Мин бүре. Мин зур, матур, чиста. | |

| | | |
|---|---|---|
| яшь | | Мультфильм: |
| | | “Җәнлекләр спорт бәйрәмендә” |
| бүре | | Аудиоязма №31-32 |
| керпе | Әтәч зур, матур | |
| | Тавык кечкенә, матур | |
| | | Аудиоязма №33-34 |
| | -Син кем? | Дәфтәрдә эш №10 |
| | -Мин үрдәк. | |
| тавык | | Мультфильм: |
| әтәч | | “Циркта” |
| үрдәк | | Аудиоязма №35 - 36 |
| | Куян чана шуа. | Дәфтәрдә эш №11 |
| | | Аудиоязма №37 - 38 |
| | Мин чана шуам. | Дәфтәрдә эш №12 |
| чана | | Мультфильм: |
| шуа | | “Шаян кошлар” |
| шуам | | Аудиоязма №39 - 40 |
| | -Аю, әйдә, бие! | |
| | | Аудиоязма №41 |
| | | Дәфтәрдә эш №13 |
| бие | | Мультфильм: |
| бии | | “Урманда зур концерт” |
| биим | | Аудиоязма №42 - 44 |

| | | |
|---|---|---|
| ак<br>кара<br><br>җырла-җырлыйм<br><br>зур рәхмәт<br><br>китап укый<br><br>рәсем ясыйм | -Оля кызыл шар ярата?<br>-Юк.<br>-Оля яшел шар ярата?<br>-Әйе, мин яшел шар яратам.<br><br>-Син нишлисең?<br>-Мин җырлыйм.<br><br>җырлыйбыз<br>зур рәхмәт<br><br>Кыз китап укый.<br><br>рәсем ясыйм-алма ясыйм<br>мәктәп<br><br>-Кем укый.<br>-Мин укыйм. | Дәфтәрдә эш №14<br><br>Аудиоязма №45 - 46<br><br>Мультфильм: “Акбай туган көнгә барырга җыена”<br><br>Аудиоязма №47<br>Дәфтәрдә эш №15<br><br>Аудиоязма №45, 48 – 49<br><br>Мультфильм:<br>“Мияуның туган көне”<br><br>Аудиоязма №50<br>Дәфтәрдә эш №16<br><br>Аудиоязма №51 - 53<br>Дәфтәрдә эш №17<br><br>Мультфильм:<br>“Урман китапханәсендә”<br><br>Аудиоязма №54 - 60<br>Дәфтәрдә эш №18<br><br>Мультфильм “Уйный-уйный укыйбыз” |

| | | |
|---|---|---|
| укыйм | бик тәмле | Аудиоязма №61-63<br>Дәфтәрдә эш №19<br><br>Мультфильм: “Урман мәктәбендә”<br><br>Аудиоязма №64 |
| дәфтәр | Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Алар бик дус. | Мультфильм: “Теремкәй”<br><br>Аудиоязма №65-66 |
| | -Кәҗә кая?<br>-Әнә, кәҗә кәбестә ашый.<br>Кәҗә кәбестә ярата.<br><br>-Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>-Мә, кәҗә, ботка аша.<br>-Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | Мультфильм: “Кем нәрсә ярата?”<br><br>Аудиоязма №67 - 71<br>Дәфтәрдә эш №20 |

## 2.2. «Туган телдә сөйләшәбез» проекты буенча эш программасы

Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу — республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен үз эченә ала. 2015—2020 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясендә дә балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максаты куелган. Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Төп максат балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге — тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру.

«Туган телдә сөйләшәбез» укыту-методик комплекты Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министр лыгының «Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата федераль дәүләт таләпләрен раслау һәм аларны гамәлгә кертү турында» 2009 ел, 23 ноябрь, 655 нче боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата федераль дәүләт таләпләре нигезендә балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде. Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- бәйләнешле сөйләм үстерү;
- тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Федераль дәүләт таләпләрендә билгеләнгән 4 төп тәрбия юнәлеше үсешенә («Физик үсеш», «Социаль-шәхси үсеш», «Танып белү – сөйләм үсеше», «Нәфис-нәфасәти үсеш») нигезләнеп, комплекслы-тематик план төзелде. Ул зурлар төркемендә 36 проектны, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 проектны һәм шул проектлар буенча төзелгән зурлар төркемендә 98, мәктәпкә әзерлек төркемендә 100 эшчәнлек конспектларын үз эченә ала.

«Минем бакчам», «Мин яратам сине, Татарстан», «Саулык – зур байлык», «Исеменә күрә – җисеме», «Кунак булсаң – тыйнак бул», «Исәнме, мәктәп», «Кояш системасы», «Дуслык белән көчле без», «Китап кайдан килә» һ.б. күп проектлар балалар һәм өлкәннәр тормышын чагылдыра, ана телен камил белергә, аның нечкәлекләренә төшенергә ярдәм итә, башка милләт халыклары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә өйрәтә, балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыра.

Укыту-методик комплекты федераль дәүләт таләпләрендә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе («Сәламәтлек», «Физик культура», «Социальләштерү», «Хезмәт», «Куркынычсызлык», «Танып-белү», «Аралашу», «Матур әдәбият уку», «Иҗат», «Музыка») буенча куелган бурычларны да күздә тотып эшләнде һәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге структурасында интегральләштереп бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә-юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел, ә рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез.

«Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны сиземләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт- итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Шушы җирдән, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Өянкеләр җырлап, таллар елап,
Сандугачлар моңы озата.

– дип, шагыйрә Клара Булатованың шигырен укыганда, балаларга туган җир, туган туфрак, туган телнең изгелеген, өянкеләрнең кайчан җырлаганын, талларның ничек итеп елаганын, сандугачларның моңы ничек итеп күңелне кузгалтканын аңлата алсак, без үз максатыбызга ирешкән булырбыз.

Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота.

Болар — «Безнең балалар бакчасы», «Көз», «Мин — дөньяныңбер кешесе», «Минем әйләнә-тирәм», «Кыш», «Яңа ел бәйрәме», «Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр», «Халык иҗаты», «Яз», «Җәй». Елга ике тапкыр

диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә, аның нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н. Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясендә чыккан «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Методик әсбапта беренче кечкенәләр төркеменә (2 яшьтән 3 яшькә кадәр) йөрүче балалар эшчәнлеген оештыруның кыскача эчтәлеге (конспектлар) бирелгән һәм нәниләрне туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү эшчәнлеге үзенчәлекләре күрсәтелгән.

**Комплекслы-тематик план**
**Зурлар төркеме**

| | Проект темалары | Эшчәнлек. Эшчәнлек төрләре | саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Минем бакчам | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт<br>Рәсем карау һәм хикәя төзү: «Балалар бакчасында»<br>Шигырь ятлау: М.Фәйзуллина.Өлкән группага күчкәч» | 1<br>1<br>1 |
| 2 | Мин яратам сине, Татарстан | Әңгәмә. «Туган ил кайдан башлана?»<br>«Башкалабыз – Казан»<br>Шигырь уку: Р.Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан» | 1<br>1<br>1 |
| 3 | Яхшы сүз – җан азыгы | Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү:Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз» | 1<br>1 |
| 4 | Абдулла Алиш иҗаты | «А.Алиш – балалар язучысы»<br>Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән аккош» | 1<br>1 |
| 5 | Хуш киләсең, ямьле көз! | Бакча тирәли сәяхәт. «Җәйләр көзләр җитте»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге табигать»<br>Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Көз» | 1<br>1<br>1 |
| 6 | Көз күчтәнәчләре | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт.<br>«Көзге могҗиза» Сәхнәләштерү: В.Хәйруллина.<br>«Яшелчәләр бәхәсе»<br>Шигырь ятлау: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә» | 1<br>1<br>1 |
| 7 | Икмәк – яшәү терәге | «Игенче хезмәте белән танышу»<br>Әңгәмә. «Икмәк – тормышның нигезе» | 1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Әкиятуку: «Икмәк».Төрекмән халык әкияте | 1 |
| 8 | Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Безнең гаилә»<br>«Әби-бабайларны хөрмәтлик»<br>Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием»<br>«Һәркемнең үз йорты бар»<br>Әңгәмә. «Йорт җиһазлары»<br>Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 9 | Табын янында | Савыт-саба кибетенә сәяхәт<br>Чагыштырма хикәя төзү: «Чәйнек белән самавыр»<br>Әңгәмә. «Мин кунак яратам»<br>Хикәя сөйләү: «Тәлинкәнең төбе нинди?» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 10 | Киемнәрдә безне бизиләр | Кием-салым кибетендә<br>Әңгәмә. «Милли киемнәр» | 1<br>1 |
| 11 | Саулык – зур байлык | «Су, һава һәм кояш – безнең белән гел юлдаш!»<br>Сәхнәләштерү: А.Алиш. «Куян кызы» әкияте<br>Шигырь ятлау: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез» | 1<br>1<br>1 |
| 12 | Исеменә күрә – җисеме | Әңгәмә. «Исемең матур, кемнәр куйган?»<br>«Без дә хокуклы» | 1<br>1 |
| 13 | Салкын кыш. | Әңгәмә. «Без суыктан курыкмыйбыз»<br>Кышкы уеннар<br>Тәҗрибә. «Предметның бер хәлдән икенче хәлгә күчүе»<br>Рәсем буенча хикәя төзү: «Кышкы уеннар»<br>Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 14 | Бездә кышлаучы кошлар | Балалар бакчасы тирәли экскурсия.<br>«Җимнәр сибәм кошларга»<br>Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә»<br>Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин. «Песнәк»<br>Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | Кыргый хайваннар | Төркемдә уен оештыру. «Зоопаркка сәяхәт»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Куяннар»<br>Әкият уку, сәхнәләштерү: «Төлке белән бүре». Татар халык әкияте<br>Әкият уку: «Бүре аларны ашаган». Болгар халык әкияте | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 16 | Йорт хайваннары һәм кошлары | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя «Ишегалдында»<br>Рәсем карау: «Песи һәм песи балалары»<br>Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү: Г.Мөхәммәтшин. «Ак песи» | 1<br>1<br>1 |
| 17 | Транспорт | «Җир өсте, һава, су транспорты»<br>Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. «Йөк машинасы һәм җиңел машина»<br>Хикәя уку: И.Дәүләтшин. «Алпамыш шәһәргә килде» | 1<br>1<br>1 |
| 18 | Юл йөрү кагыйдәләре | «Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркыныч-сызлык билгеләре»<br>Әңгәмә. «Велосипед – минем дустым»<br>Шигырь ятлау: Ш.Галиев. «Светофорның өч күзе» | 1<br>1<br>1 |
| 19 | Хезмәт төбе – хәзинә | Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау. «Хезмәткә хөрмәт»<br>Әңгәмә. «Кем булырга?»<br>Хикәя уку: К.Ушинский. «Иртәнге нурлар» | 1<br>1<br>1 |
| 20 | Кунак булсаң – тыйнак бул! | Әңгәмә. «Сүз эчендә энҗе бар»<br>Шигырь уку: В.Хәйруллина. Табын кагыйдәләре»<br>Россия – зур дәүләт «Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел ...»<br>Әңгәмә: «Теле барның – иле бар» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 21 | Батырлыкта – матурлык | «Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар»<br>Шигырь уку: Җ.Дәрзаман. «Солдат булдым» | 1<br>1 |
| 23 | Заманча әкиятләр | «Винни-пух кунакка бара» – минем яраткан мультфильмым» | 1 |
| 24. | Кояш гомере телим мин, | Әңгәмә. «Әни кирәк» | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әнием, сиңа! | Шигырь ятлау: Н.Гайсин. «Әни гөлләре» | 1 |
| 25 | Без язны яратабыз | Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Яз»<br>Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>Шигырь ятлау: М.Мазунов. «Яз килә»<br>Тәҗрибә үткәрү. «Суган утырту» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 26 | Безнең канатлы дусларыбыз | Терәк сораулар буенча рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү.<br>«Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана».<br>Уен-викторина. «Кошлар – безнең дусларыбыз!»<br>Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 27 | Хәрәкәттә – бәрәкәт | «Минем яраткан спорт төре»<br>Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Туплар» | 1<br>1 |
| 28. | Су яшәү чыганагы | Әңгәмә: «Яңгыркаем, яу, яу!»<br>Тәҗрибә. «Суның үзенчәлекләре» | 1<br>1 |
| 29 | Уттан саклан! | Әңгәмә. «Янгын куркынычсызлыгы»<br>Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле» | 1<br>1 |
| 30 | Бүлмә гөлләре | «Хуш исле нәфис гөлләр»<br>Тәҗрибә. «Кояш, су һәм һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте» | 1<br>1 |
| 31 | Галәм киңлекләре | «Планетарийга сәяхәт» уены | 1 |
| 32 | Г.Тукай иҗаты | «Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты»<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк»<br>Шигырь ятлау: З.Туфайлова. «Тукай абый» | 1<br>1<br>1 |
| 33 | Урман – җиребезнең матурлыгы, байлыгы | Урман почмагына экскурсия<br>«Камканы күзәтү»<br>«Кызыл китап нәрсә ул?»<br>Әкият эчтәлеген сөйләү: Ф.Зариф. «Татлы җәй» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 34. | Җиңү алып килде май | Сугыш ветераннары белән очрашу. «Бөек Җиңү»<br>Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай» | 1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 35. | Чәчәкләр– тормыш яме | Уен-викторина. «Чәчәкләр – тормыш яме» | 1 |
| 36. | Алдакчы, саран булма | Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир» | 1 |
| 37. | Җәй | Хуш киләсең, ямьле җәй! | 1 |

**Комплекслы-тематик план**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме**

| №п/п | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчән-лек саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Белем бәйрәме | Мәктәпкә экскурсия. «Исәнме, мәктәп!»<br>Әңгәмә. «Белем бәйрәме»<br>Хикәя уку: М.Хәсәнов. «Сара мәктәпкә бара» | 1<br>1<br>1 |
| 2 | Аралашу әдәбе | Әңгәмә. «Тәмле сүз – җан азыгы»<br>Хикәя эчтәлеген сөйләү: В.Осеева. «Тылсымлы сүз» | 1<br>1 |
| 3 | Туган ягым– яшел бишек | «Минем туган җирем «<br>Әңгәмә. «Минем гүзәл халкым»<br>«Туган ягым язучылары»<br>«Татарстан буйлап сәяхәт»<br>Әңгәмә. «Чал тарихлы Казаным»<br>Шигырь уку: Ә.Синегулов. «Татарстан җирләре» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4 | Абдулла Алиш иҗаты | А.Алиш иҗаты белән танышу.<br>Әкиятнең эчтәлеген сөйләү. «Сертотмас үрдәк» | 1<br>1 |
| 5 | Алтын көз! | Урман почмагына экскурсия.<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Алтын көз<br>Шигырь ятлау: М.Җәлил. «Көз житте» | 1<br>1<br>1 |
| 6 | Яшелчә, җиләк- җимеш | «Бакчада көзге эшләр"<br>Үз тәжрибәсеннән чыгып хикәя төзү.«Мин уңыш җыйдым»<br>Шигырь уку: Х.Халиков. «Дәү әнием – бакчачы» | 1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Көз күчтәнәчләре»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге эшләр»<br>Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Балан» | 1<br>1 |
| 7 | Икмәк – яшәү терәге | «Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә»<br>Картина карау. И.Шишкин. «Арыш басуы»<br>Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Ашлар солтаны» | 1<br>1<br>1 |
| 8. | Гаилә һәм йорт җиһазлары | «Минем өем, өй җиһазлары»<br>Әңгәмә. «Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?»<br>Иҗади хикәя төзү. «Тату гаилә»<br>Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 9. | Ашамлыклар һәм савыт- саба | Ашханәгә экскурсия<br>Әңгәмә. «Кунак чакырдык<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?» | 1<br>1<br>1 |
| 10 | Милли киемнәр | Танышу уены. «Әбиемнең серле сандыгы»<br>Чагыштырып хикәя төзү. «Кием кешене бизи»<br>Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Кәләпүшем, кәләпүш» | 1<br>1<br>1 |
| 11 | Кыш. Кышкы уеннар. | Паркка экскурсия. «Килеп житте матур кыш»<br>Әңгәмә. «Паркта минем күргәннәрем»<br>Шигырь ятлау: Г.Латыйп. «Кыш килде»<br>«Боз һәм бозлыклар»<br>Иҗади хикәя төзү. «Кышкы уеннар»<br>Язма сөйләм. «Кыш бабайга хат» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 12 | Кыргый хайваннар | «Кайда, ничек кышлыйлар?»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Кыш.Тиеннәр» | 1<br>1 |
| 13 | Кышлаучы кошлар | Кошларны күзәтү. «Безнең канатлы дусларыбыз»<br>«Кошларга ярдәм итик»<br>Калмык халык әкиятен уку: «Күңелле чыпчык белән күңелсез карга» | 1<br>1<br>1 |
| 14 | Йорт хайваннары һәм кошлары | «Авылда ишегалды» | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Картина буенча хикәя төзү: «Йорт хайваннары. Ат белән колын»<br>Әкиятнең эчтәлеген сөйләү: «Үрдәк беренчелекне алган» | 1<br>1 |
| 15 | Транспорт, юл йөрү кагыйдәләре | «Транспорт төрләре белән танышу»<br>Әңгәмә. «Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәркөнне»<br>Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Светофор | 1<br>1<br>1 |
| 16 | Һөнәрләр | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт: «Безне җырларга кем өйрәтә?»<br>Әңгәмә. «Әти-әниләр һөнәре»<br>Шигырь уку: Э.Мөэминова. «Фокусчы»<br>Укытучы хезмәте белән таныштыру:«Укытучы» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 17 | Мультфильмда кунакта | Әкиятне дәвам итеп сөйләү. «Күчтәнәч»тә кунакта»<br>Әңгәмә. «Әкиятләр иленә сәяхәт» | 1<br>1 |
| 18 | Мин дөньяның бер кешесе | Әңгәмә. «Мин бәхетле – мин хокуклы»<br>«Тигез хокук белән яшик бу җирдә» | 1<br>1 |
| 19 | Мин һәм минем сәламәтлегем | Шифаханәгә (шәфкать туташы бүлмәсенә) экскурсия. «Шәфкать туташы»<br>Фикер алышу: «Сәламәтлек – зур байлык»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: В.Монасыйпов. «Шифалы табиблар» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 20 | Муса Җәлил. Ил сакчылары | «Кемнәр алар – ил сакчылары»<br>«Муса Җәлил – бөек шагыйребез» (Сәхнәләштерү: М.Җәлил. «Карак песи»)<br>Шигырь уку: Р.Корбан. «Җәлил турында җыр» | 1<br>1<br>1 |
| 21 | Халыкара телләр көне | Фикер алышу. «Дуслык – бөек көч»<br>Әңгәмә. «Россия – безнең илебез»<br>Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә» | 1<br>1<br>1 |
| 22 | Бүлмә гөлләре | Тәҗрибә үткәрү. «Ни өчен орлыкларны,үсемлекләрне балчыкка утырталар» | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хикәя төзү: «Кактус белән фикус гөлен чагыштыру»<br>Шигырь уку: Ә.Габиди. «Минем гөлләрем» | 1<br>1 |
| 23 | Ямьле яз | Паркка экскурсия. «Туган якка яз килде»<br>Эчтәлекле рәсемнәр сериясе буенча хикәя төзү. «Яз. Сыерчыклар»<br>Шигырь уку: Н.Мәдьяров. «Көләч яз»<br>Күзәтү: «Ак болытлар ага зәңгәр күктә» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 24 | Исәнмесез, кошкайлар | Күчмә кошлар безгә яз алып килде»<br>Шигырь ятлау. Г.Юнысова. «Кара» | 1<br>1 |
| 25 | Урман. Кызыл китап | «Нәрсә ул Кызыл китап?»<br>Әңгәмә. «Урман – безнең байлыгыбыз»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү. Р.Төхвәтуллин. «Шомырт нигә елый?»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: М.Пришвин. «Алтын болын» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 26 | Китап кайдан килә | Китапханәгә экскурсия<br>Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү: «Китап кибете»<br>Шигырь уку: Х.Халиков. «Китап докторы» | 1<br>1<br>1 |
| 27 | Космос | «Нәрсә ул Кояш системасы?»<br>Әңгәмә. «Космонавтика көне»<br>Шигырь уку: Йолдыз. «Сәлам, галәм!» | 1<br>1<br>1 |
| 28 | Спорт | Казанда Универсиада»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Спорт мәйданчыгында»<br>Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Зарядкага бас» | 1<br>1<br>1 |
| 29 | Г.Тукай иҗаты | Әдәби викторина: «Мультфильмда кунакта»<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт»<br>Шигырь уку: Г.Тукай. «Эш беткәч, уйнарга ярый»<br>«Г.Тукай һәм балалар» -кичә | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 30 | 9 май – Җиңү көне | Ветераннар белән очрашу. «Алар безгә Җиңү бүләк итте» | 1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Л.Кассиль. «Күңелләрдә мәңге сакланыр» | |
| 31 | Хуш бакчам, исәнме, мәктәп! | «Без барабыз мәктәпкә»<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Һәркем эштә»<br>Шигырь ятлау: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә» | 1<br>1<br>1 |

**Комплекслы-тематик план**
**Беренче кечкенәләр төркеме**

| | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчән-лек саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Безнең балалар бакчасы | Чишенү бүлмәсен карау<br>Йомшаккай бездә кунакта<br>Кем нәрсә эшли?<br>Предметларның төсләрен тану һәм әйтү. “Паровоз” дидактик уен<br>“Үчтеки, үчтеки” такмагын уку<br>Ә.Бикчәнтәеваның “Туп-туп-тубыбыз” шигырен уку<br>Е.Батуринаның “Тупны коткарабыз” картинасын карау<br>Пирамидалар<br>С.Сөләйманованың “Ике” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>2<br>1 |
| 2 | Көз | Көзге табигать<br>Яшелчәләр:помидор, кыяр, кишер белән таныштыру<br>Рәсемдәге кошларны карау<br>Йорт хайваннарын чакыру эндәшләрен уку<br>“Җил исә” ,“Кем нәрсә ашый?” дидактик күнегүе<br>“Безнең Алсу” сериясеннән картина карау<br>Д.Гарифуллинның “Йә, алар кемнәр икән?” шигырен уку<br>Җиләк-җимешләр | 2<br>2<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>2 |
| 3 | Мин дөньяның бер кешесе | Минем исемем бар | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | З.Туфайлованың “Ул з-у-у-ур үскән” шигырен уку<br>Г.Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен уку<br>“Песи –нечкәбил” бишек җырын җырлау<br>“Бу өйдә кем яши?” дидактик уены | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 4 | Минем әйләнә-тирәм | Яраткан уен бүлмәбез<br>М.Җәлилнең “Маэмай” шигырен уку<br>М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку<br>Ж.Тәрҗемановның “Маэмай” шигырен уку<br>Алсу бездә кунакта<br>КамАЗ машинасы<br>Безнең урам<br>Әминәнең туган көненә килегез | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 5 | Яңа ел бәйрәме | Электр лампасы белән таныштыру<br>Купшы чыршы<br>Ә.Бикчәнтәеваның “Беренче адым” шигырен уку<br>Гирлянда<br>Куян чыршы янында<br>“Карга әйтә” эндәшен уку<br>Яшел чыршы<br>Песи белән кәҗә чыршы янында<br>Чыршы бизибез<br>“Тылсымлы” таякчык<br>Без музыка залында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6 | Кыш | Ап-ак кар ява<br>Кошлар<br>Алсу урамга җыена<br>Юлны чистартабыз<br>Ж.Тәрҗемановның “Йокы бабай” әкиятен сөйләү<br>Ләйлә суыктан курыкмый (рәсем буенча)<br>С.Летованың “Кар бабай” хикәясен уку | 1<br>2<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7 | Әтиләр һәм эни-ләр, бабайлар һәм | Безнең әтиләр. (Сюжетлы картинкалар карау), | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әбиләр | “Шундый ук предметны тап” дидактик уены<br>Ш.Маннурның “Яратам” шигырен уку<br>Безнең апа. (Тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү),<br>Машина һәм самолёт<br>Кәккүк – чыпчык” уены<br>“Алсу бәйрәмгә җыена” дидактик уены<br>Мәрьямне табыйк<br>Г.Таһированың “Йокла, курчак” шигырен уку<br>Безнең әниләр. (Сюжетлы  картинкалар карау),<br>Йөк машинасы(131 бит)<br>Ә.Кариның “Тавык” шигырен уку<br>Э.Шәрифуллинаның “Иң матур әни” шигырен у | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8 | Халык иҗаты | Матрёшкалар<br>Бармак уены белән таныштыру.”Йорт хайваннары” уен күнегү<br>“Йомры икмәк”рус халык әкиятен уку<br>Чуар тавык” әкиятен уку<br>“Йомры икмәк” әкиятен кабатлау<br>Теремкәй” рус халык әкиятен уку | 2<br>1<br>1<br>1<br>1<br>2 |
| 9 | Яз | Яз, яз килә<br>Җәнлекләр урманда яшиләр<br>Кына гөле<br>Сыерчыклар, карлыгачлар килде  (картинкалар карау),<br>Язгы урманда<br>Песиле тал бөреләрен карау<br>Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие, сез кайда?<br>К,Д,Ушинскийның “Казлар” хикәясен уку<br>Р.Батулланың “Нурбәк” әкиятен уку<br>“Кояш, чык, чык” эндәшен уку<br>“Тук, тук, тукран” эндәшен уку<br>“Тор – тор, тургай” такмагын ук<br>Ш.Галиевнең “Яз” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Җәй | Тузганак чәчәген карау<br>Балалар бакчасы ишегалдында<br>Ә.Кариның “Чебиләр” шигырен уку<br>Йорт хайваннары<br>Кызыксынучан тел<br>С.Сөләймерованың “Кызыл әтәч” шигырен уку<br>Балалар тавык һәм чебиләр ашата (рәсем буенча)<br>Ком һәм аның үзлекләре<br>Рәхмәт,җәй!<br>Зоопарк | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

**Комплекслы-тематик план**
**Икенче кечкенәләр төркеме**

| №п/п | Проект темалары | **Эшчәнлек төре** | Эшчән-лек саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Сау бул җәй! Исәнме балалар бакчасы. | Кояш, чык!<br>Йомшаккай әзерләгән сюрприз<br>Манара<br>“Ә” авазы<br>З.Гөмәрова “Ул шуңада кечкенә”<br>Э.Мөэминова “Үз телендә сөйләшә”<br>Ә.Бикчәнтәева “Туп” яттан өйрәнү | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 2 | Көз | Куян үстергән кишер һәм помидор<br>Сары ,кызыл яфраклар<br>Бакчада алмалар өлгерде<br>Алтын көз”Аю белән бабай” әкияте<br>Ә.Ерикәй “Көз” яттан өйрәнү<br>М.Фәйзуллина “Көзге яңгыр” уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 3 | Минем йортым, минем шәһәрем | Минем шәһәрем<br>Уенчык песи баласы турында хикәяләү | 1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Алсуның яңа өе<br>“Әлли- бәлли итәргә..” бишек җырын уку<br>Н.Каштан “Безнең сыер” шигырен уку<br>Җ.Тәрҗеманов “Үзен бик чиста йөртә” уку<br>“Олыга –утын ярырга” бармак уены | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4 | Мин һәм минем гаиләм | Безнең гаилә<br>“Баш бармак..” уку<br>Ә.Бикчәнтәева “Бәтиләр” уку<br>Ш.Маннур “Яратам” яттан өйрәнү<br>“Кем нәрсә ярата?” сөйләү | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 5 | Яңа ел бәйрәме | Тылсымлы шкатулка<br>Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз<br>Төлке бездә кунакта<br>Б.Рәхмәт “Кыш бабай” шигырен өйрәнү<br>И.Шәймөхәммәтов “мактанчык бака” әсәрен уку<br>Р.Вәлиева “Сүз тыңлаучан булыгыз” уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6 | Кыш | Чанада шуабыз” рәсемен карау<br>Җимлек янында<br>Алсуны урамга киендерәбез (Кышкы киемнәрне карау)<br>Кар ява<br>Һ.Такташ “Ләйлә! шигырен уку<br>Ж.Дәрзаманов “Алмаз”  шигырен уку<br>Ә.Бикчәнтәева “Салкын саф һава”  шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7 | Ватанны саклаучылар көне | Ватанны саклаучылар көне<br>Очучылар<br>З.Туфайлова “Шофе булам” шигырен уку<br>Ә.Исхаков “Гүзәл” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 8 | Сигезенче март | Минем әнием<br>Кояш гөмере телим мин, әнием сиңа!<br>Д. Аппаков “Рөстәм” әсәрен уку<br>“Чәбәк-чәбәк әбкәсе ..” юаткычы | 1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | З.Туфайлова “Әни сүзе” яттан өйрәнү.<br>Г.Нәбиуллина “Әнигә булышам” уку | 1<br>1 |
| 9 | Халык җәүһәрләре | Тере һәм уенчык кошларны карау<br>“Теремкәй” рус халык әкиятен сөйләү<br>Л.Толстой “Өч аю” әкияте уку<br>“Төлке, Куян һәм әтәч” әкияте сөйләү | 1<br>1<br>2<br>1 |
| 10 | Яз | Урамда яз<br>Бозау, колын, бәрән турында сөйлибез<br>Д.Гарифуллин “Тавыклар һәм Таһир” уку<br>Р.,атулла “Елак әтәч” әсәрен уку<br>Б.Рәхмәт “Яз” яттлау<br>Х.Вахит “Уңган сыерчык” уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 11 | Җәй | “Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” рәсемен карау<br>Тузганак чәчәген карау<br>Автобуста сәяхәт<br>Мин җәйне яратам<br>“Аю белән хатын” әкиятен уку<br>Җ.Тәрҗеманов “Киккирикук” уку<br>М.Мазунов “Кәҗә” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

**Комплекслы-тематик план**
**Уртанчылар төркеме**

| | Проект темалары | **Эшчәнлек төре** | Эшчән-лек саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Белем бәйрәме** | Без балалар бакчасында<br>Безнең китаплар<br>Безнең яраткан апабыз<br>Безнең уенчыклар<br>Әнәс Хәсәновның “Балалар бакчасында” хикәясен уку<br>Гасыйм Лотфиның “Ул бакчаны ярата” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | **Көз** | Басуга бару<br>Куян күчтәнәчләре<br>Көзге яфраклар. Күгәрчен<br>“Песи балалары белән” дигән сюжетлы картина карау<br>Л.Леронның “Яфрак бәйрәме” шигырен уку<br>Г.Гомәрнең “Аю Әппәс” әкиятен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 3 | **Мин дөньяның бер кешесе** | Әти, әни һәм мин<br>Мин һәм кешеләр<br>Мин үзем өчен иң кадерле кеше<br>Гаилә<br>Б.Рәхмәтнең “Бакчага киләчәк” шигырен уку. Һөнәрләр турында сөйләшү**.** | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4 | **Минем шәһәрем, минем Ватаным** | Минем данлыклы шәһәрем<br>Минем Туган илем - Рәсәй<br>Синең куркынычсызлыгың синең кулларда<br>Әхмәт Рәшитнең “Кояшлы ил” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 5 | **Яңа ел бәйрәме** | Кар кызы, кар бөртеге бездә кунакта<br>Яңа ел уенчыклары<br>Яңа ел килә<br>Киемнең үткәне һәм бүгенгесе<br>Хуш киләсең, карлы кыш!<br>Миләш һәм балан җиләкләре<br>Кыш бабай турында хикәя төзү<br>Әкияти җәнлекләрнең кышкы маҗаралары<br>Чыршыкай - купшыкай<br>Хәйдәрнең “Керпе туны” әкиятен уку<br>Мәрзия Фәйзуллинаның “Кыш бабай” шигырен ятлау<br>Әнәс Кариның “Кыш” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6 | **Кыш** | Кыш билгеләре<br>Кар бабай<br>Җәнлекләр кышка әзерләнә | 1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Җәнлекләр кышкы урманда<br>Ап-ак тунлы кыш<br>Кыргый хайваннар<br>Хәйдәрнең “Керпе туны” әкиятенең эчтәлеген сөйләү | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 7 | **Ватанны саклаучылар көне** | Без – солдатлар<br>Безнең армия<br>Бакчабызның балта остасы<br>Хәрби һөнәрләр<br>Очучылар<br>Иң яхшы әти(Йомгаклау чарасы)<br>Клара Булатованың “Солдатлар” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8 | **Сигезенче Март** | Музыка җитәкчесендә кунакта<br>Әнием турында сөйлим<br>Әниләр бәйрәме<br>“Эт көчекләре белән” дигән картина буенча хикәя төзү<br>Д. Хабибуллинаның “Бүләк” шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 9 | **Халык җәүһәрләре** | Савыт-саба<br>Бияләй һәм перчатка<br>Без әкият яратабыз | 1<br>1<br>1 |
| 10 | **Яз** | Кар бабай язны эзли<br>Яз бүләкләре<br>Яз килә, яз!<br>Аюның язгы маҗаралары<br>Урман күлендә<br>Константин Ушинскийның “Хайваннар бәхәсе” әсәрен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 11 | **Җиңү бәйрәме** | Татарстан байрагы<br>Җиңү бәйрәме<br>9 майны каршылап...<br>Транспорт<br>Әхмәт Рәшитнең “Кояшлы ил”шигырен яттан өйрәнү<br>“Тавык, Тычкан, Көртлек” татар халык әкиятен сөйләү | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12 | **Җэй** | Чәчәкләр<br>Үрдәк бәбкәсе Бак-Бакны тасвирлау<br>Бөҗәкләр<br>Чәчәкле җәй<br>“Күбәләкләр ничек килеп чыккан?” филиппин халык әкиятен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

## ТӨРКЕМНӘРДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮЗЛӘШТЕРҮ ДӘРӘҖӘЛӘРЕНӘ ДИАГНОСТИКА

### Диагностика: биремнәр, методикалар

**“Курчак турында сөйлә” диагностик биреме**

**1. “Әйтегез әле, нәрсә ул курчак” күнегүе.**

- Билгеләмә бирә (*Курчак – ул уенчык, курчак белән уйныйлар*).
- Аерым билгеләрен, хәрәкәтләрен белдерә торган сүзләрне әйтә (*Курчак матур. Ул басып тора*).
- Биремне үтәми , “курчак” сүзен кабатлый.

**2. “Курчак нинди кием кигән?” күнегүе.**

- Дүрттән дә артык сүз әйтә.
- Икедән дә артыграк киемне әйтә.
- Әйтмичә генә күрсәтә.

**3. “Курчакка ул йөгерсен, кулын селтәсен өчен бирем бир” күнегүе.**

- Дөрес формалар бирә (*Алсу, йөгер әле. Алсу, кулыңны селтә әле.*)
- Фигыльләрне генә әйтә. (*Йөгер. Селтә.*)
- Дөрес булмаган форма бирә.

**4. “Курчакка кунаклар килде. Өстәлгә нәрсәләр куярга кирәк?” күнегүе.**

- “Савыт саба” сүзен әйтә.
- Савыт – сабаның аерым предметларын әйтә.
- Бер предмет әйтә.

**5. “Нинди савыт – сабалар беләсең?” күнегүе.**

- Дүрттән артык предмет атый.
- Ике предмет атый.
- Бер предмет атый.

**6. “Нәрсәдән ясалганын әйт?” күнегүе.**

*Тәрбияче,балага көнкүрештә кулланыла торган савыт-саба предметлары күрсәтә: пыяла стакан, тимер кәстрүл, агач кашык, пластмас савыт. Тәрбияче әйтә: "Кунаклар курчакка бүләкләр алып килгәннәр. Кайсы предмет нәрсәдән ясалганын әйт".*

- Барлык предметларны атый һәм аларның нинди материалдан ясалганын әйтә.
- Ике предметны атый.
- Атамыйча гына күрсәтә.

**7. "Предметлар нәрсә белән аерылалар?" күнегүе.**

*Тәрбияче төрле савыт – саба ясалган рәсемнәр күрсәтә.*

- Төсе (формасы, зурлыгы) буенча атый.
- Аерым билгеләрен саный. ( Бу чынаяк – яшел, бу – кызыл, бу – биек.)
- Бер аермалыгын атый.

**8. "Сүзне әйтеп җибәр" күнегүе.**

Бу тәлинкә тирән, ә монысы.... *(сай)*, бер стакан биек, ә икенчесе... (*тәбәнәк*), бу чынаяк чиста, ә монысы... *(пычрак)*.

- Барлык сүзләрне дә дөрес таба.
- Ике биремне үти.
- Бер биремне үти.

**9. "Чынаякның тоткычы бар. Тагын нәрсәләрнең тоткычлары була?" күнегүе.**

- Өч – дүрт предметның тоткычын атый. *(Чәйнекнең, үтүкнең, сумканың, кулчатырның.)*
- Ике предметны атый. *(Кәстрүлнең. Табаның.)*
- Чынаякның тоткычын күрсәтә.

**"Туп турында сөйлә" диагностик биреме**

*Тәрбияче ике туп күрсәтә, һәм балага түбәндәге сораулар бирә:*

**1. "Нәрсә ул туп?" күнегүе.**

- Билгеләмә бирә. *( Туп – ул уенчык. Ул түгәрәк, резинадан ясалган).*
- Нинди дә булса билгесен әйтә.
- "Туп" сүзен кабатлый.

**2. "Нәрсә ул ыргыту, тоту" күнегүе.**

- Аңлата белә. *( Ыргыту ул – кемгә дә булса тупны ата, ә икенчесе аны тота).*
- "Ыргыттым" – дип, хәрәкәтне күрсәтә, (тупны төбәп ата).
- Хәрәкәтне күрсәтә (сүзләр әйтми).

**3. "Ике тупны чагыштыр. Алар нәрсә белән аерылалар һәм нәрсә белән охшаш?" күнегүе.**

- Билгеләрен атый. *( Икесе дә түгәрәк, резинадан ясалган; туплар белән уйныйлар.)*
- Төс буенча булган аермасын гына атый.
- Бер сүз әйтә.

**4. “Син нинди уенчыклар беләсең?” күнегүе.**
- Дүрттән күбрәк уенчык атый.
- Икедән күбрәк уенчык атый.
- Бер сүз әйтә.

**5. “Күлмәк, чалбар, кофта; чынаяк, кәстрүл, таба сүзләрен бер сүз белән ничек атарга ?” күнегүе.**
- Гомумиләштерүче сүзне атый һәм сәбәбен күрсәтә. *( Күлмәк, чалбар, кофта – **кием**. Аларны өскә кияләр. Чынаяк, кәстрүл, таба – **савыт-саба**, анда ашарга пешерәләр һәм аннан ашыйлар.)*
- Гомумиләштерүче сүзне атый.  *( Күлмәк, чалбар, кофта – **кием**. Чынаяк, кәстрүл, таба – **савыт-саба**.)*
- Гомумиләштерүче сүзне атамый.

**Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру**

**“Эт һәм көчекләр” сюжетлы картинасын карау” диагностик биреме**

**1. “Синең эт күргәнең бармы? Нәрсә ул эт? Ул нинди?” күнегүе.**
- Гомумиләштерә. *(Эт – ул хайван; эт өрә. Ул йонлач.)*
- Атый. *( Бу эт. Ул кара.)*
- Тәрбияче артыннан бер сүзне кабатлый.

**2. “Эт балаларын ничек атыйлар? Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне дөрес  әйтегез” күнегүе.**
-Эт тиз йөгерә, ә көчекләр... *(әкрен).*
-Этнең тавышы калын, ә көчекләрнеке ...(*нечкә*).
- Эт баласын дөрес атый, җөмләне тәмамлый.
- Эт баласын “көчек” дип атый.
- Бер сүз генә әйтә.

**3. “Эт нәрсә эшли белә?” күнегүе.**
- Өч-дүрт хәрәкәт атый. *(Өрә, йөгерә, сөяк кимерә. Әгәр дә эт песи күрсә, өрә һәм артыннан чаба.)*
- Ике хәрәкәт атый.
- Бер сүз генә әйтә.

**4. “Этне һәм көчекне чагыштыр. Алар нәрсә белән охшаш һәм нәрсә белән аерылалар” күнегүе.**
- Эт һәм көчек турында сөйли. *(Эт зур һәм  йонлач, көчек кечкенә һәм йомшак.)*

- Биремне тәрбияче ярдәме белән үти.
- Бер аермалыгын әйтә.

**Сөйләмнең аваз культурасы**

**“Сөйләмнең аваз ягын билгеләү” диагностик биреме**

**1. “Шар, тун, коңгыз, куян, балык, трамвай, лампа, көрәк сурәтләнгән картинкалар күрсәтү” күнегүе.**

*Тәрбияче балага картинкада нәрсә сурәтләнгәнен атарга куша. Тәрбияче бала әйтә алмаган авазларны билгели.*

- Барлык авазларны да әйтә.
- Сонор һәм чыжылдаучы кебек катлаулы авазларны әйтә алмый.
- Сонор авазларны да  һәм чыжылдаучы авазларны да әйтә алмый.

**2. “Үзеңә таныш булган юаткычны тиз, әкрен, тыныч һәм кычкырып әйт” күнегүе.**

- Текстны ачык итеп әйтә.
- Ачык итеп әйтми, тавышның көчен дөрес көйләми.
- Текст әйтелешендә җитди кимчелекләр бар.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү**

**“Хикәяләү (тасвирлау һәм сюжетлы хикәяләү) һәм эчтәлек сөйләүне билгеләү” диагностик биреме**

**.1. “Курчакны тасвирла” күнегүе.**

*(Тәрбияче курчакны күрсәтә.)*

-Курчак нинди, аның белән нәрсә эшләргә була, аның белән ничек уйныйлар? Шул турыда сөйлә.

- Курчакны мөстәкыйль тасвирлый. *(Бу курчак. Ул матур. Аның исеме – Алсу. Курчак  белән уйнарга була. Яки: Бу курчак. Аның исеме Алсу. Курчакның чәчләре озын. Күлмәге кызыл. Курчак белән уйнарга була.)*
- Педагог ярдәме белән сөйли.
-Җөмлә төземичә генә аерым сүзләр әйтә.

**2. “Туп турында сөйлә” күнегүе.**

-Ул нинди, ни өчен кирәк, аның белән нәрсә эшләргә була.
- Тасвирлый. *(Бу – туп. Ул түгәрәк, зур-кечкенә, резинадан ясалган, кызыл төстә. Аны ыргытырга һәм тотарга була. Ул уйнар өчен кирәк.)*
- Билгеләрен атый. *(Кызыл, резинадан ясалган).*
- Аерым сүзләр әйтә, ләкин алардан җөмлә төземи.

**3. “Уенчык эт турында хикәя уйлап чыгар” күнегүе.**

- Хикәя уйлап чыгара.
- Сыйфатларын һәм хәрәкәтләрен атый.
- 2-3 сүз әйтә.

**4.” Хикәя төзе” күнегүе.**

Тәрияче балага, “Мин ничек уйныйм”, “Минем гаиләм”, “Минем дусларым” дигән темаларның берсенә, хикәя төзергә тәкъдим итә**.**

- Хикәяне мөстәкыйль төзи.
- Зурлар ярдәме белән сөйли.
- Сорауларга бер сүз белән җавап бирә.

**5. “Эчтәлеген сөйлә” күнегүе.**

Тәрбияче кыска хикәя яки әкият укый һәм аның эчтәлеген сөйләргә тәкъдим итә.

- Эчтәлекне мөстәкыйль сөйли.
- Тәрбияче әйтеп җибәргән сүзләрне кулланып сөйли.
- Аерым сүзләр әйтә.

**Диагностика үткәрүгә аңлатма.**

Биремнәрне бәяләү баллар белән күрсәтелә:

-— баланың дөрес, төгәл, мөстәкыйль җаваплары өчен 3 балл куела;

– тәрбиячәнең этәргеч сораулары буенча җавап биргән һәм зур булмаган төгәлсезлекләр җибәргән балага2 балл куела;

– баланың җаваплары зурлар биргән сорауга туры килмәсә, сүзләрне тәрбияче артыннан кабатласа, сорауны аңламаганын күрсәтсә, 1 балл куела.

Тикшерү ахырында балларны санау үткәрелә:

- Әгәр күпчелек җаваплар 3 баллга тиң булса ( 2-3 тән күбрәк), - бу югары дәрәҗә.
- Әгәр яртысыннан күбрәге 2 балл булса, - бу уртача дәрәҗә.
- Әгәр 1 баллы җаваплар күп икән,- бу уртачадан түбән дәрәҗә.

**Эчтәлек үзләштерү дәрәҗәләре:**

**Югары** – сөйләм осталыгына ия; әкиятләр, хикәяләр уйлап чыгарганда инициатива, мөстәкыйльлек күрсәтә (хикәянең структурасы турында күзаллаулары бар), башкаларның хикәяләрен кабатламый, сәнгатьлелекнең төрле чараларын куллана; эчтәлек сөйләгәндә, башы, уртасы, ахыры кебек текстның структур өлешләрен төгәл саклап, текст эчтәлеген эзлекле итеп бирә; сүзлек запасы бай; сөйләме сәнгатьле, грамматик яктан дөрес.

**Уртача** – үзе уйлап чыгарганда, хикәяне тасвирлаганда, әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, төшереп калдырулар урын алып тора, логик хаталар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә ул аларны үзе төзәтә; бик актив булмаса да, сөйләмдә аралашуга кызыксынуы бар; җөмлә төзегәндә кыенлыкларга очрамый,  грамматик хаталар сирәк була; сөйләмнең сәнгатьлелеге җитәрлек дәрәҗәдә түгел.
**Түбән** –  эчтәлек сөйләгәндә бәйләнешләр урнаштыруда кыенлыклар кичерү сәбәпле,  мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча хаталар җибәрә, сөйләү барышында тәрбияче ярдәменә мохтаҗ; үзе  экиятләр, хикәяләр, кызыклы хәлләр турында сөйләгәндә, тасвирламалар төзегәндә структур өлешләрне төшереп калдыра, мөстәкыйльлеге дә җитәрлек түгел (иптәшләренең хикәяләрен кабатлый); сүзлек запасы ярлы; грамматик хаталар җибәрә; сөйләме сәнгатьле түгел.

## Кулланылган әдәбият

1. Әдәп – матур гадәт: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен  методик кулланма / Төз.: З.М.Зарипова.- Яр Чаллы, 2009.
2. Әхлак белеме: кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары, ата-аналар, укытучылар, сыйныф җитәкчеләре, балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм педагогик уку йортлары студентлары өчен хрестоматия / Төз.: В.С.Казыйханов.- Яр Чаллы, 2000.- 188 б.
3. Бала бишеге – гомер ишеге: башлангыч сыйныф укытучылары, балалар бакчаларында, милли төркемнәрдә тәрбиячеләр, ата-аналар  өчен халык авыз иҗаты әсәрләре җыентыгы / Төз.: Ф.Зарипова, иҗади  төркем.- Яр Чаллы: Идел-йорт, 2000.- 130 б.
4. Балалар бакчасы: ата-аналар һәм татар балалар бакчалары өчен  хрестоматия / Төз.: Ф.Ю.Юсупов.- Казан: Раннур, 2002.- 650 б.
5. Балалар бакчасында татарча сөйләм үстерү дәресләре: балалар  бакчаларында  эшләүче  тәрбиячеләр  өчен  методик кулланма  /  Төз.:  З.М.Зарипова, А.И.Касыймова.- Казан, 2010.
6. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / М.А.Васильева, В.В.Гербова, Т.С.Комарова ред.; 4 нче русча басмадан  К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, З.Г.Ибраһимова, Г.Р.Гыйләҗетдинова, Ф.Җ.Җәләлетдинова тәрҗ.- Казан: Мәгариф, 2006.- 286 б.
7. Бал бабай: балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен кулланма / Төз.: З.М.Зарипова,  И.М.Хәмитов.- Яр Чаллы, 2000.- 167 б.
8. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз.: К.В.Закирова, Р.А.Борһанова.- Казан: Хәтер, 2000.- 192 б.

9. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / Төз.: К.В.Закирова.- Казан: РИЦ, 2011.- 560 б.
10. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик кулланма / Төз.: З.М.Зарипова, иҗади төркем.- Яр Чаллы, 2000.- 70 б.
11. Бородич А.М. Методика развития речи детей.- Москва: Просвещение, 1981.- 255с.
12. Гөлбакча (балалар бакчалары өчен хрестоматия): балалар бак чаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма / Төз.: Ф.Ю.Юсупов, З.Ф.Камалова, Р.А.Борһанова.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.- 254 б.
13. Закирова К.В., Гаффарова С.М. Әткәм-әнкәмнең теле: балалар бакчасы тәрбиячеләренә кулланма.- Казан: Мәгариф, 1997.- 152 б.
14. Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез (балалар бакчасында уеннар): балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2005.- 175 б.
15. Иң матур сүз: ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия / Төз.: К.В.Закирова.- Казан: Мәгариф, 2000.- 335 б.
16. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.- 488 б.
17. Кашапова М.Ф. Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: монография.- Казан: РИЦ «Школа», 2009.- 160 б.
18. Кашапова М.Ф. Иң гүзәл тел – туган тел: балалар бакчасында сөйләм телен үстерү буенча методик кулланма.- Казан: РИЦ «Школа», 2009.- 200 б.
19. Кашапова М.Ф. Иң татлы тел – туган тел: балалар бакчалары өчен сөйләм үстерү буенча методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2004.- 446 б.
20. Кашапова М.Ф. Уйныйк әле, балалар: 1 нче китап.- Казан: РИЦ, 2011.- 216 б.
21. Программа по обучению детей русскому языку / Сост.: З.М.Зарипова, Л.З.Галиуллина, Д.Г.Мансурова, С.Г.Хисамутдинова, А.М.Лотфуллина, Г.Х.Сулейманова, Р.М.Алексеева, Е.И.Муллахметова, Л.З.Касаева.- Набережные Челны, 2004.- 111 с
22. Раушан көзге (татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия): педагогика училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма / Төз.: Р.Ш.Халикова.- Казан:Мәгариф, 1993.- 255 б.
23. Татар халык табышмаклары.- Яр Чаллы: Идел-йорт, 2000.- 96 б.
24. Татар халык уеннары / Төз.: Р.Ягъфәров.- Казан: Мәгариф, 2002.- 159 б.
25. Театр уйнап үсәбез: балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр өчен ярдәмлек / Төз.: А.Т.Хуҗина.- Яр Чаллы, 009.- 58 б.

26. Туган телем – бөек анам теле: татар балаларын ана теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма / З.М.Зарипова җитәкчелегендә.- Яр Чаллы, 2004.- 127 б.
27.Туган телдә сөйләшәбез (4-5 яшь):методик әсбап/Ф.В.Хәзрәтова,З.Г.Шәрәфетдинова.-Казан,2013.-256 б.
28.Туган телдә сөйләшәбез (3-4яшь):методик әсбап/Ф.В.Хәзрәтова,З.Г.Шәрәфетдинова.-Казан,2013.-224 б.
29.Туган телдә сөйләшәбез (2-3 яшь):методик әсбап/Ф.В.Хәзрәтова,З.Г.Шәрәфетдинова.-Казан,2012.-191 б.
30.Туган телдә сөйләшәбез (5-7 яшь):методик әсбап/З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева.-Казан,2012.-304 б.
31. Ушакова О.С. Развитие речи дошкольников.- Москва, 2011.- 237 с.
32. Ушакова О.С., Струнина Е.М. Диагностика речевого развития дошкольников.- Москва: Академия, 1999.- 160 с.
33. Шәехова Р.К., Закирова К.В. Иҗат баскычлары: мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре тәрбиячеләренә, башлангыч сыйныф укытучыларына һәм әти-әниләргә тәкъдим ителә.- Казан: РИЦ «Школа», 2001.- 61 б.
34. Юлда йөрсәң, уяу бул: балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма / Төз.: .Л.Гыйниятуллина. - Яр Чаллы, 2008.- 64 б.
35. Ягъфәров Р.Р. Ал кирәк, гөл кирәк (уеннар китабы): укытучылар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма / Р.Р.Ягъфәров.- Казан: Мәгариф, 1995.- 126 б.
36. Ягъфәров Р.Р. Кәҗә-мәкәрҗә: балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма.- Казан: Мәгариф, 1994.- 110 б.

## 2.3. Милли – төбәк компоненты

**Милли-төбәк компонентын балалар бакчасы шартларында тәрбия һәм белем бирүдә куллану**

**Милли-төбәк компоненты буенча тәрбия-белем бирү эшен тормышка ашыруның төп юнәлешләре:**

- ТР яшәүче халыкларның милли мәдәниятенә, гореф-гадәт, йолаларга нигезләнеп эхлакый сыйфатлар булдыру;
- мәктәпкәчә белем бирүдә бертигез күләмдә татар һәм рус телләре өйрәтү;
- туган як табигатенә кагылышлы башлангыч белем бирү;
- Татарстан Республикасының тарихы белән таныштыру, башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

- әйләнә-тирә дөнья турында белемнәрен киңәйтү;
- балаларда гади тарихи күзаллаулар формалаштыру;
- үз гаиләсенең, ыруының тарихын өйрәнү аша балаларда өлкән буыннарның тәҗрибәсенә һәм гореф-гадәтләренә, үз халкына мәхәббәт тәрбияләү; гаилә традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру,

- Әлмәт шәһәре, аның истәлекле урыннары турында сөйләү;
- милли традицияләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру;
- туган телне өйрәнү белән беррәттән, икенче телне өйрәнү;
- балаларда башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Эффектлы нәтиҗә:**

- балаларның туган як, туган шәһәр, анда яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, милли киемнәре, туган якның тарихы турында белемнәре формалашачак;
- балалар һәм әти-әниләр төрле күргәзмәләрдә, конкурсларда, дискуссияләрдә актив катнашачаклар;
- балаларда өлкәннәр белән аралаша белү күнекмәләре формалашачак;
- балаларда өлкәннәргә, ветераннарга ихтирамлы мөнәсәбәт, хөрмәт итә белү тәрбияләнәчәк.

**Куелган бурычларны уңышлы үтәү өчен шартлар:**

- педагогларның төпле белемле булуы;
- кирәкле методик комплект булдыру;
- махсус предметлы-үстерешле мохит булдыру;
- төрле учреждениеләр, әти-әниләр белән хезмәттәшлек итү

**Милли-төбәк юнәлеше буенча уку елына перспектив план**

| Вакыты | Чаралар |
|---|---|
| Сентябрь | 1.Тылсымлы журнал белән ”Тылсымлы очрашу”;<br>“Тылсымлы куллар “ бездә кунакта. ” Балалар белән мастер-класс үткәрү.<br>2.“Төрле халык әкиятләре” альбом булдыру. |
| Октябрь | 1. “Сөмбелә” бәйрәме үткәрү. Максат:ел фасылларына караган халык бәйрәмнәре турында белемнәрен киңәйтү.<br>2. “Минем кече туган илем” почмагында эш (уеннар, альбомнар, открыткалар карау);<br>3. “Әлмәт» буйлап сәяхәт” ачык дәрес. Максат:Әлмәт шәһәре, аның тарихи-истәлекле урыннары белән таныштыруны дәвам итү,белемнәрен баету, системалаштыру. Туган шәһәргә ярату, горурлык, дуслык хисләре тәрбияләү.<br>4. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган “Җиңү шатлыгы” проекты эшен башлап җибәрү. Максат:туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Җиңү көненә багышланган |

| | |
|---|---|
| | бәйрәм турында мәглумат бирү. |
| Ноябрь | 1.“Казанга сәяхәт” уены (рәсемнәр, слайдлар карау);<br>2. “Әнием-кадерлем!” әниләр көненә бәйрәм уздыру;<br>3. Әниләр белән мастер-класста катнашу. |
| Декабрь | 1. Әти-әниләргә консультация “Әби-бабайларның тәрбия үрнәге бүгенге көндә дә актуаль»;<br>2. “Хуш киләсең яңа ел” бәйрәм;<br>3.Бөек Ватан сугышы темасына кагылышлы китаплар күргәзмәсе булдыру. |
| Январь | 1.“Дәү әни” белән “Күчтәнәч” бездә кунакта (балалар белән халкыбызның сәнгать төре-чигү үрнәкләре күрсәтү);<br>2.Әти-әниләргә консультация “Халкыбызның чигү тарихы”. |
| Февраль | 1. Әти-әниләр өчен киңәшләр “Табигать белән аралашуның балалар тәрбияләүдәге әһәмияте”<br>2.“Мин булачак ил сакчысы!” күңел ачу кичәсе. Максат:Ватанны саклаучылар турындагы күзаллауларын киңәйтү. Балаларда батыр, кыю солдат булу теләге уяту, әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү.<br>3. “Муса Җәлил- бөек шагыйр ” М.Җәлил турында фильм карау. Максат: балаларның күзаллауларын үстерү. Шагыйрнең батырлыклары турындагы белемнәрен киңәйтү. |
| Март | 1. Әңгәмә: “Дуслык-бөек көч” (Төрле халыкның милли киемнәре төшерелгән слайдлар карау). Максат:төрле милләт халыкларына хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү. Идел буе халыклары турында балаларның белемнәрен баету.<br>2. “Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!” әниләр бәйрәме. Максат: әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.<br>3. Бөек Ватан сугышы музей-мемориаленә һәм Кремльгә экскурсия. Максат:балаларның татар халкының тарихы турында күзаллауларын үстерү, татар халкының батыр сугышчылыры турында, музейда үз-үзеңне тоту культурасы буенча белемнәрен арттыру.<br>4.Тыл ветераннары: Ахметгалиева Магианвар Файзрахмановна, күренекле шәхес Андреева Людмила Сергеевнаны балалар белән очрашуга чакыру. Максат: кем ул “тыл ветераны?” Балаларның күзаллауларын үстерү. Аларның батырлыклары турында белемнәрен киңәйтү. Тыл ветераннарына хөрмәт уяту. |
| Апрель | 1. Композитор, ТАССР ның, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, тыл ветераны, сугыш чоры баласы Имашев Мәсгуд Габдрахманович белән очрашу. Максат:танылган шәхес, тыл ветераны турында кызыксынучанлыкларын үстерү. Ветераннарга хөрмәт тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| | 2. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең музей-квартирасына экскурсия. Максат: М.Җәлилнең иҗаты, тормыш юлы турындагы белемнәрен киңәйтү. Якташыбыз, патриот шагыйрь белән горурлану хисләре тәрбияләү.<br>3. Балалар һәм әти-әниләр катнашында "Җиңү шатлыгы"рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе оештыру;<br>4. 27 нче гимназия укучылар белән берлектә ветераннар өчен төрле халык җырларыннан торган музыкаль кичә оештыру. Максат:балаларда патриотик хисләр, дуслык, әхлаклылык хисләре тәрбияләү.<br>5."Г.Тукай безнең безнең күңелләрдә" шигырь бәйрәме уздыру. Максат: Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү. Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру. |
| Май | 1. "Җиңү алып килде май" бәйрәм кичәсе. Максат:җиңү көненә багышланган бәйрәм турында мәгълумат бирү.<br>2. Сугыш һәм тыл ветераннары белән очрашулар. Максат:балаларда Ватанга мәхәббәт, патриотик хисләр, кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү.<br>3.Әти-әниләр өчен консультация:"Сабантуе йоласының символик мәгънәсе".<br>4.Сәхнәләштерү:М.Җәлил."Кызыл ромашкалар". Максат:балаларда патриотик хисләр тәрбияләү, шигырьне сәхнәләштерү аша балаларда артислык күнекмәләрен үстерү. |

## III. Оештыру өлеше

### 3.1. Методик киңәшләр, эшне оештыру

Методик кулланмаларда 60 ар белем бирү эшчәнлегенең конспектлары бирелгән. Ел дәвамында, тәрбияче үзе иҗади якын килеп, укыту методик кулланмада бирелгән тематик планга таянып, мультфильмнар, анимацион сюжетлар, "Әкият илендә" тапшыруын кулланып, индивидуаль эшне дә кертеп, көндәлек план төзи.

Телгә өйрәтүнең төп формасы һәм чарасы булып белем бирү эшчәнлеге алына. Ул системалы рәвештә план буенча үткәрелә. Өйрәнелгән сүзләр, сүзтезмәләр, диалоглар эшчәнлектән тыш уен вакытларында активлаштырыла һәм ныгытыла, көндәлек аралашуда кулланыла.

Яңа сүзләрне, сүзтезмәләрне, ситуацияләрне балалар аңламаган очракта, тәрбияче рус телендә сөйли.

Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла.

Балаларга темадан тыш артык сүзләр, уеннар, җырлар, шигырьләр бирелергә тиеш түгел.

Бала татар телендә сүзне дөрес әйтмәгән очракта, тәрбияче баланы тыңлап сүзнең дөрес үрнәген бирә. Балалардан авазларның дөрес әйтелешен катгый таләп итмәскә кирәк.

Тәрбияче сөйләмендә акцент, җирле диалект, аваз кимчелекләре булмаска тиеш.

Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала.

Тәрбияче үзенең эшенә иҗади якын килергә, төрле алымнар, чаралар эзләп, аларны кулланырга тиеш.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана.

Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр,сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм әти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә.

**Сүзлек белән эшләү.**

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана.

Яңа сүзләр үзләштерү процессында махсус сайлап алынган күнегүләр төп чара булып тора. Юнәлеше һәм характеры ягыннан лексик күнегүләрне икегә бүлеп карыйлар: әзерлек күнегүләре һәм сөйләм күнегүләре.

*Әзерлек күнегүләре* балаларны яңа сүзләрне файдаланып сөйләргә әзерли. Бу күнегүләр лексик берәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр.

*Сөйләм күнегүләре* лексик күнегүләрнең бер төре буларак, үзләштерелгән лексик берәмлекләр җирлегендә ситуацияләргә бәйле сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерәләр.

Яңа сүз өйрәтү төп методик алымнарның берсе булып тора:

-яңа сүз тәрбияче тарафыннан ачык, төгәл итеп күрсәтмә рәсем ярдәмендә әйтелә;

-аудиоязмадан тыңлатыла, кабатлатыла;

-ишеткән сүзне бала рәсемннән табып күрсәтә һәм әйтә;

-сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә;

-төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә;

-уеннар кулланып ("Ватык телефон", "Кайтаваз"...) ныгытыла;

-яңа сүз, таныш булган сүзләр белән грамматик конструкцияләрдә ныгытыла, мәсәлән: зур туп, чиста туп;

-аралашуда кулланыла (бала өйрәнгән яңа сүзләрне, конструкцияләрне бары аралашуда аңлап куллана).

-бала теге яки бу сүзне аның төгәл мәгънәсен аңлап үзләштереп калсын өчен телдән мондый күнегүләрне үткәрергә мөмкин: -*Бу туп? - Әйе, бу туп.*

*-Бу песи? (туп күрсәтелә) - Юк, бу песи.*

-өйрәнелгән сүзләрне хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырырга була: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин” һ.б..

Баланың сөйләмен оештыру өчен исемнең алмашлык (мин, син, бу), сан (1 дән 10 га), сыйфат (тәм, күләм, төс, эчке сыйфатлар) һәм фигыль белән бәйләү грамматик конструкцияләре кулланыла.

Фигыль белән таныштыру боерык фигыльләрдән башлана (бар, сикер, аша һ.б.).

Уртанчылар төркемендә балаларга боерык фигыльләрне аңлап үтәүләрен таләп ителә.

Зурлар төркемендә балалар кайбер боерыкларны үзләре бирә (сикер, аша, уйна) һәм аңлап үтиләр.

Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә балалар үзлектән Нишли? Син нишлисең? сорауларын бирәләр һәм аңлап җавап кайтаралар.

Укыту методик комплектының төп асылы булып аралашуга чыгу тора. Аралашуга чыгу өчен диалогик сөйләмнең әһәмияте бик зур. Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә гадидән катлаулыга дигән дидактик принципка таянып эшләү улай.

Диалогик сөйләмдә иң отышлы алым – сорау-җавап рәвешендә (сорау-информация алу бирәмлеге) һәм теләк белдерә торган: теләк, үтенү, тәкъдим итү, ризасызлык төсмере булырга мөмкин. Еш кына сораудан соң, әңгәмәдәшнең җавап репликасы; килә: *Бу кем?- Бу әти;* раслау рәвешендә: *Бу әти?- Әти;* инкарь рәвешендә: *Бу әни?- Юк, бу әти.*Реплика- җавап сорау рәвешендә дә булырга мөмкин: *Нинди әти?* Бу вакытта әңгәмәдәшнең җавабы тулы да, ким дә булырга мөмкин: *Матур әти;* яисә: *Матур.*

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ситуатив - тематик принцип нигезендә, диалогик сөйләмне үстерү буенча түбәндәге типтагы күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин:
- уен ситуацияләрендә катнашу;
- тәкъдим ителгән үрнәк буенча кечкенә диалоглар төзү;
- тематик диалоглар төзү;
- сәхнәләштерүдә катнашу;
- рольләргә бүлеп сөйләү.

Диалоглар белән эшләү коммуникатив юнәлештә алып барылырга тиеш. Тәрбияче аларның балалар сөйләменә кирәрлек кирәкле формаларын эшләргә һәм төрле шартларда куллану мөмкинлеген исәпкә алырга тиеш. Тәрбияче, сөйләмгә эмоциональ бизәлеш өстәү өчен, төрле формаларны кулланырга; эш эчтәлегенә туры килә торган интонация, ишарәләр, мимикалардан файдаланырга һ.б. өйрәтергә тиеш.

Шул ук вакытта, диалогны сорау бирү һәм аңа җавап алу дип кенә уйларга ярамый. Балаларны диалогик сөйләмгә хас булган башка (сорау һәм җаваплардан тыш) ситуацияләр, репликалар, көндәлек аралашу формаларына да өйрәтергә кирәк.

Диалог үрнәкләре:

Исәнләшү: *Исәнме, Оля! – Исәнме Коля.*
Саубуллашу: *Сау бул, Оля. – Сау бул Коля.*
Танышу: *Мин Оля. – Мин Коля.*
Чакыру: *Оля, кил монда.*
Рәхмәт белдерү: *Мә, курчак. – Рәхмәт*.
Сорау- уңай җавап: *Син малай? – Әйе, мин малай*.
Сорау – кире җавап: *Син малай? – Юк, мин кыз.*
Ачыклый торган сорау: *Мин кафега барам. – Нинди кафега?*

**Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар тора.**

**Аудиоязмалар** яңа сүз өйрәтү, сөйләм үрнәкләре үзләштерү, уеннар, кыска җырлар өйрәтү, өстәл театры күрсәтү вакытларында куллану өчен төзелде. Аларны һәр эшчәнлектә куллану мөһим түгел.

**Эш дәфтәрләре** эшчәнлектә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелде. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер-берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Балалар үзләренең эш дәфтәрләрен өйгә алып кайтып өйрәнелгән материалны кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән эти-әниләр дә, төркем тәрбиячеләре дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылды.

Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән. Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этәрәбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 2-нче зат алмашлыгына тәңгәл формада (яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1-нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм һ.б.). Балалар бер-берсенә, өлкәннәргә сораулар бирергә өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б. Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар. Мәсәлән: Аю караватта йоклый. Куян чана шуа. Песи бит юа һ.б.. Мәктәпкә әзерлек төркемендә өченче бирем җыр формасында бирелә.Бу биремнәрне интерактив такта һәм экраннарда эшләп була.

**Анимацион сюжетлар** балаларның белгән сүз байлыгына, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелде. Сюжетны караганнан соң, балалар белән әңгәмәләр үткәрелә, алда өйрәнелгән уен ситуацияләрен кабатларга тәкъдим ителә.

“Татарча сөйләшәбез” укыту методик комплектына нигезләнеп эшләнгән “Әкият илендә” телевизион тапшыруын балаларны татар теленә өйрәткәндә карарга тәкъдим ителә.

## 3.2. МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ (АРАЛАША) БЕЛҮ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ.

**Тикшерү үткәрү буенча киңәшләр.**

Балаларның татар телендә аңлау һәм сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен уку елы башында (октябрь ае) һәм уку елы ахырында (апрель аенда) тикшерелә. Уртанчылар төркеме балалары белән тикшерү уку елы ахырында үткәрелә. Уку елы уртасында тематик тикшерү (декабрь, январь) үткәререгә мөмкин.

Тикшерүне һәр бала белән аерым, 1 – 2 бала катнашында, ә йомгаклау эшчәнлеге булганда барлык балалар белән бергә дә үткәрергә була. Тикшерү вакыты 10-15 минутан артмаска тиеш.

Биремнәр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә, уен-бирем рус телендә аңлатыла. Биремнәр мавыктыргыч һәм кызыклы булырга тиеш. Сораулар ачык, төгәл итеп, интонация белән бирелә.Тикшерүче балаларның җавабын тыңлаганда елмаеп, кирәк булса җавапны дөресләп, бала әйтә алмаганда булышырга тиеш.

Тикшерү барышында яңа материал бирелми. Тикшерүне эш дәфтәрләре, таратма, күрсәтмә рәсемнәр, интерактив тактада уеннар кулланып үткәрергә дә була.

Биремнәр, уеннар өчен кирәк булган күрсәтмәлелек алдан әзерләнеп куелган булырга тиеш. Тикшерүче һәр биремгә аерым балл куеп бара. Тикшерү ахырында баллар саны кушыла һәм 5 кә бүленә. Шулай итеп гомуми нәтиҗә ясала.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының**
**“Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Баланың исеме, | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |

| | фамилиясе | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.**

1. “**Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

***<u>1. Дидактик уен. "Бу кем?"</u>*** *<u>(I вариант)</u>*

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)

Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).

***<u>2. Дидиктик уен "Кем юк?"</u>*** *<u>(II вариант)</u>*

(Лексика шул ук).Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)

Уенны интерактив тактада да, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була)

***3. Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"***

(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)

***4. Дидактик уен "Нәрсә юк?"***

Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...) Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.

***5. Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"***

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай; куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).

Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.

***6. Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Тәрбияче өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны(рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?"- "Алма"... ; "Бу кем?"-"Әти"... Бала уенчык исемен дөрес әйтсә аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.

***7. Дидактик уен "Серле янчык"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.

***8. Дидактик уен "Әйе-юк"***

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?" - "Аю"...; "Бу аю?" - "Әйе, аю"...; "Бу куян?" - "Юк, песи"...

**Югары балл (2.7-3)** — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.

**Уртача балл (2-2,6)** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”).**

**3. *Ситуатив күнегүләр:***

а) Ситуатив күнегү “Куян аюга кунакка килә”. Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?), "Исәнме аю".

б) Ситуатив күнегү “Куян аюда кунакта булды”. Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) "Сау бул, аю".

в) Уен ситуациясе "Кунак сыйлау". Акбайда (Мияуда) кунакта.
Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән "сыйлый". Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.
г) Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла". Балаларны парлаштырып бер-берсен сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.
д) Ситуатив күнегү "Акбайга ("Мияуга", "Курчакка", "Дустына") уенчык бүләк ит".
**Югары балл (2,7-3)** - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
**Уртача балл (2-2.6)** - тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**Уртачадан түбән (1-2)** - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

**3. Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч).**

**1. Сүзле уен "Мин әйтәм - син эшлә" ("Командир").**
**2. Сүзле уен "Шаян уенчыклар"** (Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерү өчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык “ашый” башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).
**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - бала боерыкны аңлап, дөрес үти.
**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - ялгыша.
**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

**4.Тирә-юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.**

***1. Дидактик уен "Уенчык нинди?" (зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).***
Уен эчтәлеге: зур-кечкенә уенчыклар күрсәтелә. Тәрбияченең "Нинди?" соравына бала уенчыкның исемен сыйфат билгесе белән әйтергә тиеш.
-Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.
Эш дәфтәрендәге 11 нче биремне кулланып була.

***2. Дидактик уен "Тап, күрсәт һәм әйт" (чиста, пычрак).***
Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә.("Чиста туп", "Пычрак аю"...).
Эш дәфтәрендәге 13 нче биремне кулланып була.

***3. Дидактик уен "Курчакка бүләк".***
Тәрбияче зур курчакка- зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша. “ Мә, зур туп ", “Мә, кечкенә туп".

***4. Дидактик уен "Дөрес сана".***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. "Ничә малай?", "Ничә кыз?".

***5. Дидактик уен "Ничә?".***

Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була.

- Ничә туп? - Биш туп.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөрес әйтә.

**Уртача дәрәҗә (2-2.6)** - 1-2 билгесен әйтә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).**

***1. Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә. К нам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться: - Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля (Коля). -Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай (әйе, мин кыз).

***2. Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз ".***

а) Тәрбияче: К нам идут гости.

***Спроси. "Кто там?". "Кем анда?"*** - Мин әби (бабай).

***"Позови бабушку (дедушку)".*** - Әби (бабай) кил монда.

***"Поздоровайся с бабушкой (дедушкой)"*** - Исәнме, әби (бабай).

***"Спроси у бабушки (дедушки) как дела?"*** - Әби (бабай) хәлләр ничек? - Әйбәт, рәхмәт.

***"Предложи бабушке (дедушке) сесть".*** - Әби (бабай) утыр.

***"Предложи бабушке (дедушке) пить чай"*** - Мә, чәй, эч.

***Скажи: "До свидания!"*** Сау бул, әби! (бабай).

б) Балага "кунак" белән исәнләшергә, хәлен сорарга, чакырып утыртырга, сыйларга ("аша,эч") һәм саубуллашырга тәкъдим ителә.

Эш дәфтәрендәге 3 нче биремне кулланып була**.**

***1. Уен ситуациясе "Кунакларны сыйла".***

***Угости Акбай хлебом, Мияу молоком***.

-Мә, Акбай ипи, аша. - Рәхмәт.

-Мә, Мияу сөт, эч. - Рәхмәт.

Эш дәфтәрендәге 16 нчы биремне кулланып була**.**

***2. Уен ситуациясе "Бер - береңне сыйла ".***

*(Ашамлык муляжлары кулланып)*

***"Угости яблоком".***
- Мә, алма, аша. - Рәхмәт.
***"Спроси, яблоко вкусное?"***
- Алма тәмле? - Әйе, тәмле.
Эш дәфтәрендәге 6 нчы биремне кулланып була**.**

***3. Уен ситуациясе "Уенчыклар илендә"***

***1 . Ты пришел в магазин игрушек. Попроси игрушку, которая тебе нравится***.
-Куян бир (әле).- Рәхмәт.
***2. Предложи поиграть с игрушкой.***
- Мә, туп, уйна. - Рәхмәт.
***3. Позови друга, предложи помыть игрушку.***
-Коля, кил монда. - Мә, туп, ю.
***4. Поменяйтесь игрушками. Попроси у друга игрушку, предложи ему свою .***
- Коля, туп бир - Мә, туп.
- Рәхмәт.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.
**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

**Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының**

| № | Баланың исеме, | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |

| | фамилиясе | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белу (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белу (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля... | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

**1.“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**
**(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

1. ***Дидактик уен “Бу нәрсә?”***

(Лексика: аш, ботка, сөт, кашык, тәлинкә, чынаяк).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? (“Аш”...)

2. ***Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: “Нәрсә бар?” (“Кәбестә”...)

3. ***Дидактик уен “Нәрсә юк?”.***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***<u>Дидактик уен "Дөресен әйт".</u>***

(Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, караватт).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрнең исемен атый һәм күрсәтә.

**<u>Югары балл (2.7-3)</u>** — сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә һәм куелган сорауларга җавап бирә.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** - аңлый, русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану ("Исәнме", "Сау бул", "Рәхмәт", "Исәнмесез", " Сау булыгыз").**

***Ситуатив күнегүләр (уртанчылар төркемендәге ягымлы сүзләр бүлеген кара):***

а) Поздоровайся с Акбаем.
б) Спроси как дела у Акбая.
в) Скажи спасибо Акбаю. Спроси как дела.
г) Попрощайся с Акбаем.
д) Поздоровайся с воспитателем, Мияу и Акбай.
е) Попрощайся с воспитателем, Мияу и Акбай.
**<u>Югары балл (2.7-3)</u>** — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** – уен ситуацияләрен тәрбияче ярдәмендә төзи.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** – аңлый, җавап бирә алмый.

**3. Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал).**

Балаларның боерыкларны бирә белү күнекмәләрен тикшерү. Балалар бер-берсенә боерык бирәләр. Саша, аша! – Саша ашау хәрәкәтләре күрсәтә. Алга таба Саша үзе башка балага боерык бирә һәм шундый тәртиптә дәвам ителә.
(Лексика: кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал).
**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – 8-9 сүз.
**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – 5-6 сүз.
**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – 1-2 сүз.

**4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).**

***1. Сюжетлы-рольле уен “Кибет”***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куя белүләрен максат итеп куясың. Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары рәсемнәре кулланып үткәрелә.
(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

***2. Дидактик уен “Нинди?”.***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.
Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сораугa аңлап җавап бирү һәм ул сорауларны үзлектән куя белү.
(Лексика: нинди? кызыл, сары, яшел, зәңгәр).

**3.** ***Дидактик уен “Ничә?”.***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

*4.* ***Дидактик уен “Дөрес сана”.***

Тәрбияче уенчыклар, муляжлар, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне санарга тәкъдим итә. Балалар бер-берсенә сорау бирәләр һәм җавап бирәләр. Шулай ук, сорауны тәрбияче үзе дә бирә ала. *“Ничә...?”*.

**Югары балл (2,7-3)** – диалогта 3 сорауны да аңлап куллана**.**

**Уртача балл (2-2.6)** – диалогта 2 сорауны аңлап куллана**.**

**Уртачадан түбән (1-2)** – диалогта 1 сорауны аңлап куллана**.**

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау).**

***1. Уен ситуациясе “Әйдәгез танышабыз”.***

“Син кем?” соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.
К вам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться:

- Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля яки Коля).
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай).

***2. Уен ситуациясе “Кунак каршылыйбыз”.***

а)Тәрбияче:

- К нам идут гости. Спроси. “Кто там?”. “Кем анда?”
- Мин Акбай.
- Позови Акбая.
- Акбай, кил монда.

б)У Акбая сегодня день рождение. Подари свою игрушку

- Акбай, мә кызыл туп.
- Рәхмәт.

в) Угости гостей супом или кашей.

- Мә, аш (ботка) (аша).

г)Что бы сьесть угощение попроси ложку.

- Кашык бир.
- Нинди кашык?
- Зур, матур, зәңгәр кашык.
- Рәхмәт.

3. ***Уен ситуациясе “Кибеттә”.***

Бала белән бала аралашуы тикшерелә.

- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Аю бир.
- Нинди аю?
- Зур аю, чиста аю, матур аю.
- Ничә?
- Ике аю.
- Мә, ике аю.
- Рәхмәт.
- Сау бул.

**Югары балл (2,7-3)** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.
**Уртача балл (2-2.6)** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**Уртачадан түбән (1-2)** – аңлый, русча җавап бирә

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Баланың исеме, | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | баллар | дәрәҗә |

| | фамилиясе | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**1.“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча  биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

***1. Дидактик уен “Бу нәрсә?”***

(Лексика: тычкан, бүре, төлке, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, аю).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:

- Бу нәрсә? (“бүре”...)

***2. Дидактик уен “Портфельдә нәрсә бар?”***

(Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, мәктәп).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче портфельдән рәсемнәр яки предмет алып күрсәтә, исемен сорый:

-Портфельдә нәрсә бар?- (“Дәфтәр бар”...)

***3. <u>Дидактик уен “Портфельдә нәрсә юк?”</u>***

Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

***4. <u>Дидактик уен “Дөресен әйт”</u>***

(Лексика: чәк- чәк, өчпочмак, бәрәңге, аш, ботка, су).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый.
**<u>Югары балл (2.7-3)</u>** — 10-14 сүз.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** – 7-9 сүз.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** – 1-6 сүз.

**2. Ягымлы сүзләр куллану**
**(“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Зур рәхмәт”, “Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”)**

***<u>Ситуатив күнегү:</u>***

Телефоннан сөйләшү.
Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне кулланып була**.**
**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** – аңлый, сорауларга җавапны русча бирә.

**3. Боерыкны бирә белү.**

(Лексика: кил монда, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).

***<u>Дидактик уен: “Командир”</u>***

Эш дәфтәрендәге 9 нчы биремне кулланып була**.**
Бер бала икенче балага боерык бирә. Мәсәлән:
-Коля, сикер! (Коля сикереп күрсәтә).
-Коля, син нишлисең?(Колядан сорый) – Мин сикерәм.
-Коля нишли? (Башка баладан сорый) – Коля сикерә.
**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** — 11-13 сүз белән боерык бирә, син нишлисең, нишли сорауларын бирә белә.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** – бары боерык бирә, сорауларны куя алмый.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** – 1-5 сүз белән боерык бирә, сорауларны русча әйтә.

**4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү.**

**(Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)**

***<u>1. Уен ситуацияләре:</u>***
а) “Кибет” (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)
б) “Телефоннан сөйләшү” (Кая барасың? Син нишлисең?)
в) “Танышу” (Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли?)

***2. <u>Сюжетлы-рольле уен “Кибет”</u>***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куллана белүләре тикшерелә.Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары, йорт кошлары, уенчык рәсемнәре кулланып үткәрелә.
(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

***2. <u>Дидактик уен “Нинди?”.</u>***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.
(Лексика: кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара).

***3. <u>Дидактик уен “Сана”.</u>***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).
**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – сорауларны аңлап куллана**.**
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** – аңлый, тәрбияче ярдәме белән куллана**.**
**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – русча җавап бирә.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау)**

***1. <u>Уен ситуациясе “Әйдәгез танышабыз”</u>***
- Исәнмесез. Син кем? - (Мин Оля яки Коля).
- Мин кыз. Син кыз? - (Юк, мин малай).
- Сиңа ничә яшь?- (6 (7) яшь).

***2. <u>Уен ситуациясе “Телефоннан сөйләшү”.(диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була)</u>***
- Исәнме. Хәлләр ничек?
- Әйбәт.
- Нишлисең?
- Мин уйныйм. Син нишлисең?

- Мин ашыйм.
- Нәрсә?
- Алма ашыйм.
- Алма тәмле(ме)?
- Әйе, алма тәмле.
- Сау бул.

3. ***<u>Уен ситуациясе “Кая барасың?”</u>*** (*мәктәп, кафе, цирк һ.б.*)
- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Кая барасың?
- Кафега барам.
- Кафеда нәрсә бар?
- (ашамлыклар атарга мөмкин)
- Саша нишли?
- Саша бәрәңге ашый.

4.***<u>Ситуатив күнегү.</u>***

а) Син нишлисең?
- Мин бииим (утырам, сикерәм, ашыйм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм).

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.
**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – аңлый, русча җавап бирә.

### 3.3. Методик әсбаплар

**«Минем өем» проекты:**

1) Аудиоматериал – 64 кисәк (ТРЭК),
2) Мультипликацион сюжет – 11 данә,
3) Эш дәфтәре – 17 бирем,
4) Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде),
5) Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 62 (269).

**«Уйный – уйный үсәбез» проекты:**

1)Аудиоматериал – 63 кисәк (ТРЭК),
2)Мультипликацион сюжет – 15 данә,
3)Эш дәфтәре – 19 бирем,
4)Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде),
5)Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 46 (406).

**«Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты:**
1)Аудиоматериал – 71 кисәк (ТРЭК),
2)Мультипликацион сюжет – 19 данә,
3)Эш дәфтәре – 20 бирем,
4)Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде),
5)Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 60(483 сүз булган).

**3.4.Милли состав**

| төркемнәр / милләт | Татар төркеме | Рус төркемнәре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мәктәпкә әзерлек | Беренче кечкенәләр | Икенче кечкенәләр | Уртанчылар | Зурлар | Васильево |
| татар | 10 | 7 | 12 | 10 | 11 | 2 |
| рус | 3 | 4 | 7 | 12 | 9 | 8 |
| Катнаш никах | 4 | 4 | 4 | 5 | 4 | - |
| Балалар саны | 17 | 18 | 23 | 27 | 24 | 10 |
| Барлыгы | | 129 | | | | |

**3.5.Файдаланылган әдәбият:**

*Борһанова Р. А., Юсупов Ф. Ф.* Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. – Казан: РИЦ «Школа», 2004.
*Иванова Л. Ф.* Программа обучения английскому языку в дошкольном образовательном учреждении Республики Татарстан “First Steps in English”. – Казань, 2011.
Л. С. Выготский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов,
*Е. А. Пассов* “Основы коммуникативной методики обучения иноязычному общению”. - Москва, 1989.
Балачак аланы: татар балалар балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. –Казан:РИЦ,2012.
З.М.Зарипова.Логоритмика в развитии детей дошкольного возраста, г.НабережныеЧелны,2010.

Р.К.Шаехова.Игровые технологии развитии школьно – значимых функций у дошкольников.Казань,Школа,2006.
З.М.Зарипова,Э.В.Тарасова.Триста шестьдесят пять игр для дошколят. НабережныеЧелны,2009.
З.М.Зарипова,И.М.Хәлитов. Бал Бабай.Балалар бакчалары өчен хрестоматия. Яр Чаллы,2010.
"Балачак - уйнап-көлеп үсәр чак" К.В. Закирова, Л.Р.Мортазина(Балалар бакчасында уеннар).
Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү (Программаның милли-төбәк юнәлеше) /Төз.-авт.: К.В.Закирова, Р.А.Борһанова, Г.Ә.Галиева. – Казан: Мәгариф, 2009.
Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. М.А.Васильева, В.В.Гербова, Т.С.Комарова ред.,( Русча басмадан К.В.Закирова, Р.Щ.Кадыйрова, З.Г.Ибраһимова, Г.Р. Гыйләҗева, Ф.Җ. Җәләлетдинова тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2006.)
Программа по обучению детей русскому языку / Сост.:З.М.Зарипова, Л.З,Галиуллина, Д.Г.Мансурова,Л.З.Касаева.-Набержные Челны, 2004.-163с.
Галеев Э. Х. Татарские народные игры и праздники: кн. Для учителя / Э. Х. Галеев, Я. И. Ханбиков. – 2-е изд., перераб. идоп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985.
Закирова К. В. Уйный-уйный үсәбез: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма / К. В. Закирова. – Казан:Татар. кит. нәшр, 2010.